12 октября 1875 года И. А. Бодуэн де Куртенэ переезжает в Казань, работает в Казанском университете, где возглавляет вновь созданную кафедру сравнительного языковедения. 1875–1883 годы – период напряженной научной и педагогической деятельности учёного. Блестяще теоретически и методически подготовленный, выпускник университетов Европы и Петербурга Бодуэн де Куртенэ объединяет вокруг себя молодых преподавателей и студентов, организует новое научное направление – Казанскую лингвистическую школу. Вместе с учениками он заложил основы фонологии, морфонологии, теории словообразования, лингвистической типологии и др. В значительной степени определил пути развития языкознания в XX веке. Школа была одной из первых российских научных школ.


ТРУДЫ
ФИЛОЛОГИЧЕСКІЕ и ЛИНГВИСТИЧЕСКІЕ,
помѣщенные въ изданіи
„RAD JUGOSLAVENSKE AKADEMIJE ZNANOSTI I UMJETNOSTI," U ZAGREBU, 1876—1877 г.
А. И. Бодуэна-де-Куртенэ
Отдѣльный Оттискъ изъ „Филологическихъ Записокъ."
ВОРОНЕЖЪ.
Въ Типографіи Губернскаго Правленія.
1879.




ТРУДЫ
ФИЛОЛОГИЧЕСКІЕ и ЛИНГВИСТИЧЕСКІЕ,
помѣщенные въ изданіи
„RAD JUGOSLAVENSKE AKADEMIJE ZNANOSTI I UMJETNOSTI.“ U ZAGREBU, 1876—1877 г.

А. И. Бодуэна-де-Куртенэ

Отдѣльный Оттискъ изъ „Филологическихъ Записокъ.“

ВОРОНЕЖЪ.
Въ Типографіи Губернскаго Правленія.
1879.

И. А. Бодуэн де Куртенэ – крупнейший специалист по теоретическому, сравнительному и славянскому языкознанию. Он совершил переворот в науке о языке: до него в лингвистике господствовало историческое направление – языки исследовались исключительно по письменным памятникам. Учёный в своих работах доказывает, что сущность языка – в речевой деятельности: необходимо изучать живые языки и диалекты. Только так можно понять механизм функционирования языка и проверить правильность лингвистических теорий.

В 1883 году Бодуэн де Куртенэ уезжает из Казани. Впоследствии он работает в университетах Дерпта, Кракова, Петербурга, Варшавы. И везде вокруг него объединяются молодые талантливые учёные. Однако прежде всего он известен как основатель Казанской лингвистической школы.

В 1887 году Бодуэн де Куртенэ избирается действительным членом Краковской академии, в 1897 – членом-корреспондентом Санкт-Петербургской Академии наук; в 1901 году избирается почётным членом Казанского университета.

В 1913 году Бодуэн де Куртенэ публикует брошюру «Национальный и территориальный признак в автономии», где отстаивает право наций на самоопределение.

И. А. Бодуэн де Куртенэ скончался 3 ноября 1929 года в Варшаве.

*Укырга тәкъдим итәбез:*
*Советуем прочитать:*

**Бодуэн де Куртенэ:** «Стою за полную национальную свободу и самоопределяемость каждого гражданина» //Татарстан. – 1992. – № 3. – С. 52–60.





**Бодуэн де Куртенэ** и современная лингвистика: к 140-летию со дня рождения И. А. Бодуэн де Куртенэ: сборник статей. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. – 191 с.

**Байрамова Л. К.** Казанская лингвистическая школа: учеб. пособие. – Казань: Центр инновационных технологий, 2012. – 152 с. – И. А. Бодуэн де Куртенэ. – С. 9–51.

**И. А. Бодуэн** де Куртенэ и мировая лингвистика: Международная конференция (V Бодуэновские чтения): Казанский федеральный университет. 12–15 октября 2015 г. Труды и материалы. – Т.1. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2015. – 376 с.

**Труды представителей** Казанской лингвистической школы: хрестоматия. – Т.1. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2015. – 400 с.

**Труды представителей** Казанской лингвистической школы: хрестоматия. – Т.2. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2016. – 400 с.

**Куницын Б. И.** А. Бодуэн де Куртенэ и национальный вопрос //Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2009. – № 2. – С. 207–212.

**Шарафутдинов З., Ханбиков Я.** История педагогики Татарстана. – Казань, 1998. – 307 с. – И. А. Бодуэн де Куртенэ – педагог и методист. – С. 196–210.

**В знак благодарности**: [28.10.2012 г. на здании Казанского федерального ун-та открыта мемориальная доска основателю Казан. лингвистической школы И. А. Бодуэну де Куртенэ] //Республика Татарстан. – 2011. – 29 окт.

**15** март/марта



Шамил Зиннур улы Закиров
Шамиль Зиннурович Закиров
1945—2012

Тууына 75 ел
75 лет со дня рождения

Театр эшлеклесе, педагог Шамил Зиннур улы Закиров 1945 елның 15 мартында Татарстан АССРның Чистай районы Нарат-Елга авылында туа. 1962–1963 елларда Чистай районындагы авыл мәктәбендә рус теле укыта.

1970 елда С. М. Киров исемендәге Казан химия-технология институтын, 1972 елда Н. К. Крупская исемендәге Ленинград мәдәният институты аспирантурасын тәмамлый.

1969–1972 елларда ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетында пропаганда һәм мәдәният-масса эшләре бүлеге инструкторы булып эшли. 1975 елдан Ш. З. Закиров Казан мәдәният институтында укыта башлый. 1979–1982 елларда Чаллы шәһәрендә «Энергетик» мәдәният сарае директоры, 1982 елдан халык депутатларының Чаллы шәһәр Советы башкарма комитетында мәдәният бүлеге мөдире булып эшли.

1985 елның 4 февралендә Ш. З. Закиров Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры итеп билгеләнә. Әлеге вазыйфада 27 ел эшләү дәверендә ул үзен талантлы җитәкче, чын мәгънәсендә профессионал, иҗади шәхес итеп таныта. Шамил Зиннур улы репертуарга, театрда яңа юнәлешләр эзләп табуга, квалификацияле кадрлар сайлауга зур әһәми-







*Марсель Сәлимҗанов белән*

ят биреп, яшь актёрлар һәм режиссёрларны аерым игътибар үзәгендә тота. Театрның материаль-техник базасын ныгытуга керткән өлеше дә бик зур аның.

Ш. З. Закиров бик күп театр фестиваль-бәйгеләрендә, бөек татар артистлары, режиссерлары, язучыларының истәлеген мәңгеләштерү чараларында башлап йөрүче һәм оештыручы була. Халыкара «Нәүрүз» төрки халыклар театрлары фестивале, «Яңа татар пьесасы» бәйгесе, С. Сәйдәшевкә багышланган сәнгать бәйрәме, «Гаяз Исхакый укулары» кебек иҗат проектлары әнә шундыйлардан.

Ш. З. Закиров җитәкчелегендә Г. Камал театры Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләренә, Латвия, Азәрбәйҗан, Үзбәкстан, Финляндия, Германия, Бөекбритания, Колумбия кебек илләргә гастрольләргә бара, фестивальләрдә катнаша. Татар диаспорасы вәкилләре генә түгел, сәнгать сөюче барча халык иң өлкән татар театры тамашачысына әйләнә.

Ш. З. Закиров кырык елдан артык гомерен Татарстан Республикасы мәдәнияте һәм сәнгатенә хезмәт итүгә багышлый. Аңа Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемнәр бирелә.

Шамил Зиннур улы Закиров 2012 елның 26 февралендә вафат була.



Туфан Миңнуллин һәм Рифкать Исрафилов белән



Истәлекләр китабы

Театральный деятель, педагог Шамиль Зиннурович Закиров родился 15 марта 1945 года в деревне Нарат-Елга Чистопольского района Татарской АССР. В 1962–1963 годах работает учителем русского языка в сельской школе Чистопольского района.

В 1970 году заканчивает Казанский химико-технологический институт им. С. М. Кирова, в 1972 году – аспирантуру Ленинградского государственного института культуры им. Н. К. Крупской.

В 1969–1972 годах работает инструктором по культурно-массовой работе Татарского обкома ВЛКСМ. С 1975 года Ш. З. Закиров занимается преподавательской деятельностью на кафедре культурно-просветительной работы Казанского государственного института культуры.

В 1979–1982 годах – директор Дома культуры «Энергетик» в городе Набережные Челны, затем заведующий отделом культуры Исполнительного комитета городского Совета народных депутатов города Набережные Челны.

4 февраля 1985 года Ш. З. Закиров назначается директором Татарского государственного академического театра им. Г. Камала. За 27 лет работы в должности директора театра он проявляет себя как талантливый руководитель, профессионал, творческая личность. Шамиль Зиннурович придаёт большое значение формированию репертуара, поиску новых







*Ш. Закиров, Б. Поюровский, Л. Шакирҗан, Ф. Бикчәнтәев*

театральных форм, подбору квалифицированных кадров, уделяя особое внимание молодым актёрам и режиссёрам. Неоценим его вклад в укрепление материально-технической базы театра.

Ш. З. Закиров является инициатором и организатором многочисленных театральных фестивалей, конкурсов, мероприятий по увековечению памяти великих татарских артистов, режиссёров, писателей, среди которых международный фестиваль театров тюркских народов «Науруз», конкурс «Новая татарская пьеса», творческие проекты «Праздник искусств, посвящённый С. Сайдашеву», «Чтения Гаяза Исхаки».

Под руководством Ш. З. Закирова театр успешно гастролирует и участвует в фестивалях по всему миру: Москва, Санкт-Петербург, Латвия, Азербайджан, Узбекистан, Финляндия, Германия, Великобритания, Колумбия. Зрителями старейшего татарского театра были не только представители татарской диаспоры, но и широкая многонациональная аудитория почитателей театра.

Более 40 лет профессиональной деятельности Ш. З. Закиров посвятил культуре и искусству Республики Татарстан. Ему присвоены почётные звания заслуженного работника культуры Татарской ССР и заслуженного работника культуры Российской Федерации.

Шамиль Зиннурович Закиров умер 26 февраля 2012 года.

*Укырга тәкъдим итәбез:*
*Советуем прочитать:*

**Балкыш:** Шамил Закировка бер дога: истәлекләр. – Казан, 2017. – 207 б.

**Арсланов М. Г.** Татар театры: энциклопедик сүзлек-белешмә. – Казан, 2014. – 584 б. – Закиров Шамил Зиннур улы. – Б. 225–226.

**Г. Камал исемендәге** Татар дәүләт академия театры. 2 томда. Т. 2. – Казан: Заман: Татар. кит. нәшр., 2009. – 368 б.: ил. – Закиров Шамил Зиннур улы. – Б. 64. – Текст парал. на рус.

**Фәйзуллин Р.** Юксыну //Казан утлары. – 2017. – № 7. – Б. 160–164.

**Кыдашева З.** Күләгәдәге министр //Мәдәни җомга. – 2015. – 13 март. – Б. 11.

**Таҗетдинов Р.** Сагынабыз //Мәдәни җомга. – 2015. – 13 март. – Б. 11.

**Батулла Р.** Шамил //Мәдәни җомга. – 2015. – 13 март. – Б. 11.

**Шакирҗан Л.** Сары розалар аны хәтерләтә //Мәдәни җомга. – 2015. – 13 март. – Б. 11.

**Сәләхов Б.** Ул минем укытучым //Сәхнә. – 2017. – № 3. – Б. 28–29.

**Хәбибуллина Л.** Изгелек эшләргә яратылган зат иде // Шәһри Казан. – 2015. – 13 март. – Б. 3.

**30** март/марта



Фатих Кәрими
Фатих Карими
1870—1937

Туына 150 ел
150 лет со дня рождения

Мәгърифәтче педагог, нашир, язучы, журналист Фатих Гыйльман улы Кәрими (Кәримов) 1870 елның 30 мартында Самара губернасы Бөгелмә өязе (хәзер Татарстан Республикасының Әлмәт районы) Миңлебай авылында ахун гаиләсендә туа. Башлангыч белемне өйдә әтисеннән ала. Аннары Чистайның «Камалия» мәдрәсәсендә 11 ел укый, бер үк вакытта рус теле һәм әдәбияты дәресләренә дә йөри. 1892–1896 елларда Истанбулда чиновниклар тәрбияли торган югары уку йортында укый. Анда фәннәр үзләштерүдән тыш гарәп, фарсы, төрек, француз телләрен өйрәнә.

Истанбулдан Россиягә кайткач, Ф. Кәрими 1896–1898 елларда Кырымда җәдит мәдрәсәсендә укыта.

1899 елның февраль-май айларында ул алтын прииcкалары хуҗасы Ш. Рәмиевнең тәрҗемәчесе булып Европа илләре буйлап сәяхәт итә, Көнбатышның гыйлем-мәгърифәте, мәдәнияте, мәгарифе белән таныша. Аның бу сәяхәттән алган тәэсирләре соңыннан «Аурупа сәяхәтнамәсе» исемле китабында чагыла.

1899 елның июль аенда Ф. Кәриминең әтисе гаиләсе белән Оренбург шәһәренә күчеп килә. Фатих, Каргалы бистәсендә җәдит мәктәпләре өчен укытучылар әзерләүче җәйге курслар-



*«Шура» журналы һәм «Вакыт» газетасы идарәсендә*



*Фатих Кәрими гаиләсе белән*

да укыта. Әтисе Фатихны наширлек һөнәренә өйрәтү максаты белән башта Мәскәүдә бухгалтерия курсларында, аннары С. -Петербургта И. М. Бораганскийның типографиясендә укытып кайтара.

1900 елда аталы-уллы Кәримиләр, Оренбургта типография ачып, 1901 елдан татар китаплары бастыру эшенә керешәләр. 1902 елда әтисе вафат булгач, бу эш тулысынча аның улы кулына күчә.

Бу вакытларда инде Ф. Кәрими әдәби әсәрләр авторы – язучы буларак та танылып өлгерә. 1898–1908 еллар арасында аның «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәдрәсәсендә укуы» (Петербург, 1898), «Бер шәкерт илә бер студент» (Казан, 1899), «Салих бабайның өйләнүе» (Оренбург, 1901), «Морза кызы Фатыйма» (Казан, 1907), «Хыялмы, хакыйкатьме?» (Казан, 1908) һ. б. хикәяләре һәм повестьлары басылып чыга.




1906–1917 елларда Ф. Кәрими Оренбургта чыккан, шул за-

манның популяр газетасы булган «Вакыт»та баш редактор булып эшли, шушы газета һәм «Шура» журналы битләрендә күпсанлы публицистик мәкаләләрен, очеркларын бастыра.




Ф. Кәрими җәмәгать һәм сәясәт эшчәнлеге дә алып бара: 1906 елда мөселманнар әдәби түгәрәген оештыра; 1906 дан «Иттифак әл-мөслимин» партиясе Үзәк Комитеты әгъзасы була; 1906–1917 елларда Оренбург мөселманнары корылтайларында (1905, 1906, 1914, 1917) катнаша. 1917 елның маенда 1 нче Бөтенроссия мөселманнары корылтаенда Оренбург делегатларыннан Милли Шура әгъзасы итеп сайлана.

1917–1924 елларда ул Оренбургның төрле уку йортларында укыта, газеталарында языша.

1925 елда Ф. Кәрими Мәскәүгә күчеп, СССР Халыклары Үзәк нәшриятында эшли, Шәрык институтында төрек теле дәресләре алып бара. Бер үк вакытта ул бу елларда тәрҗемә белән шөгыльләнә, педагогикага кагылышлы китаплар яза.

Фатих Гыйльман улы Кәрими 1937 елның 4 августында Мәскәүдә кулга алына, 27 сентябрьдә төрек шпионы буларак хөкем ителә, шул ук көнне атып үтерелә. 1959 елның 8 декабрендә СССР Югары судының Хәрби коллегиясе тарафыннан аның исеме аклана.

1998 елдан Татарстан Республикасы Әлмәт районының Миңлебай авылында Ф. Кәрими музее эшли.

Педагог-просветитель, издатель, писатель, журналист Фатих Гильманович Карими (Каримов) родился 30 марта 1870 года в деревне Миннибаево Бугульминского уезда Самарской губернии (ныне Альметьевский район Республики Татарстан) в семье ахуна. Начальное образование получает

дома под руководством отца. Затем 11 лет учится в медресе «Камалия» в г. Чистополе, одновременно посещает занятия по русскому языку и литературе. В 1892–1896 годах Фатих Карими обучается в Стамбуле в высшей школе по подготовке чиновников. Он владеет арабским, персидским, турецким и французским языками.

После возвращения в Россию в 1896–1898 годах преподает в медресе в Крыму.

В феврале-мае 1899 года Ф. Карими в качестве переводчика вместе с золотопромышленником Ш. Рамеевым совершает путешествие по Европе, знакомится с западной культурой и просвещением. Впечатления о поездке он описывает в книге «Путешествие в Европу».

В июле 1899 года семья Ф. Карими переезжает в Оренбург. Фатих преподает на летних курсах по подготовке учителей новометодных школ в Каргалинской слободе. С целью изучения издательского дела его отец отправляет на курсы бухгалтеров в Москву, затем в типографию И. М. Бораганского в Санкт-Петербурге.

В 1900 году отец и сын Каримовы в Оренбурге открывают собственную типографию, в 1901 году приступают к изданию книг на татарском языке. В 1902 году, после скоропостижной смерти отца, Фатих Карими возлагает на себя руководство типографией.




К этому времени Ф. Карими уже известен как автор художественных произведений. В 1898–1908 годы изданы его рассказы и повести: «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәдрәсәсендә укуы» («Учеба Джигангира-махдума в сельском медресе», Петербург, 1898), «Бер шәкерт илә бер студент» («Шакирд и студент», Казань, 1899), «Салих бабайның өйләнүе» («Женитьба Са-

лих бабая», Оренбург, 1901), «Морза кызы Фатыйма» («Дочь мурзы Фатима», Казань, 1907), «Хыялмы, хакыйкатьме?» («Сон или явь», Казань, 1908) и др.




В 1906–1917 годах Ф. Карими – редактор газеты «Вакыт» («Время»), одной из самых популярных татарских газет того периода. На страницах газеты и журнала «Шура» писатель публикует свои многочисленные статьи и очерки.

Ф. Карими активно занимается общественной и политической деятельностью: в 1906 году организует мусульманский литературный кружок; с 1906 года является членом ЦК партии «Иттифак аль-муслимин»; в 1917 году – председатель Бюро оренбургских мусульман; избирается делегатом на всероссийские съезды мусульман (1905, 1906, 1914, 1917). В мае 1917 года на Первом Всероссийском мусульманском съезде Ф. Карими избирается членом Всероссийского мусульманского совета (Милли Шура) от города Оренбурга.

В 1917–1924 годах Ф. Карими преподает в различных учебных заведениях Оренбурга, сотрудничает с газетами.

С 1925 года живёт в Москве, работает в Татарском отделении Центрального издательства народов СССР, преподает турецкий язык в Восточном институте, занимается переводами, пишет работы по педагогике.

4 августа 1937 года в Москве Ф. Карими был арестован по обвинению в шпионаже в пользу Турции, приговорен к смертной казни и расстрелян 27 сентября этого же года.

8 декабря 1959 года решением Военной коллегии Высшего суда СССР был реабилитирован.

С 1998 года в деревне Миннибаево Альметьевского района Республики Татарстан работает музей Фатиха Карими.

*Укырга тәкъдим итәбез:*
*Советуем прочитать:*

**Кәрими Ф.** Морза кызы Фатыйма: сайланма әсәрләр / төз., иске язмадан заманчага күчерүче, аерым сүзләргә аңлатма бирүче һәм кереш сүз авт. М. Гайнетдинов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 414 б.

**Кәрими Ф.** Салих бабайның өйләнүе // Гайнуллин М. Татар әдәбияты. XIX йөз. – тулыландыр. 2-нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. – Б. 678–687.

**Кәрими Ф.** Салих бабайның өйләнүе; Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы; Бер шәкерт илә бер студент // Татар мәгрифәтчелек әдәбияты (1860–1905). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – Б. 220–229; 230–245; 246–263.

**Фатыйх Кәрими**: фәнни-биогр. җыентык = Фатих Карими: науч. – биогр. сб. /сост. Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, С. Рәхимов. – Казан: Рухият, 2000. – 320 б.: Фото. б-н.

**Әдипләребез**: биобиблиогр. белешмәлек. 2 томда. Т.1 / [төз. Р. Н. Даутов, Р. Ф. Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 751 б. – Фатих Кәрими. – Б. 704–706.

**Даутов Р. Н., Нуруллина Н. Б.** Совет Татарстаны язучылары: биобиблиогр. белешмәлек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 639 б. – Фатих Кәрими. – Б. 270–272.

**Гайнуллин М.** Фатих Кәрими //Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. Т.2: XIX йөз татар әдәбияты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – Б. 334–350.

**Гайнуллин М.** Татар әдәбияты. XIX йөз. – тулыландыр. 2-нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. – 690 б. – Фатих Кәрими. – Б. 671–677.

**Гайнуллин М.** Татар әдипләре (иҗат портретлары). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 280 б. – Фатыйх Кәрими. – Б.50–78.

**Харрасова Р.** Фатих Кәрими //Татар әдәбияты тарихы. 8 томда. Т.3: XIX йөз. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – Б. 423–439.





**Гайнетдин М.** Гасырлар мирасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 319 б. – Фатих Кәрими. – Б. 128–141.

**Әхмәтҗанов М.** Фатыйх Кәрими мирасына яңа сәхифәләр //Казан утлары. – 1999. – № 6. – Б. 177–182.

**Гайнуллин М. Х.** Татарская литература XIX века. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. – 307 с. – Фатих Карими. – С. 241–249.

**Якупова Г. К.** Дискуссии писателей в контексте татарской духовной жизни начала XX века (на примере Г. Исхаки, Ф. Карими и др.). – Казань, 2008. – 147 с.

**Шарипов А.** Литература народов Поволжья и Приуралья. Ч. 1: Татарская литература: история и современность. – Наб. Челны, 2018. – 571 с. – Фатих Карими. – С. 136–140.



**5** апрель/апреля



Татарстан Республикасы
Милли музее
Национальный музей
Республики Татарстан
1895

Ачылуына 125 ел
125 лет со дня открытия

Татарстан Республикасы Милли музее – Россиянең иң өлкән һәм аеруча билгеле музейларыннан берсе – Урта Идел һәм Урал буеның матди һәм рухи мәдәнияте һәйкәлләрен саклаучы үзәк булып тора.

Аңа 1894 елда Казан шәһәр фәнни-сәнәгать музее буларак нигез салына. 1895 елның 5 апрелендә музей тантаналы шартларда ачыла.

Музейның нигезен А. Ф. Лихачевның шәхси җыелмасы һәм 1890 елгы Казан шәһәр фәнни-сәнәгать күргәзмәсе экспонатлары тәшкил итә.

Музей эшләвенең беренче унъеллыгында табигать-тарих һәм тарих-этнография җыелмаларын интенсив төзү бара. Музей фондларын төзү һәм формалаштыру башында Казан университетының атаклы галимнәре Н. Ф. Высоцкий, Н. П. Загоскин, Н. Ф. Катанов, А. А. Штукенберг һ. б. тора. Музей тупланмаларын Казан коллекционерлары һәм меценатлары В. И. Заусайлов, О. С. Александрова-Гейнс, Г. Галиев (Баруди), Д. И. Образцов һ. б. актив рәвештә тулыландыра.

Музейның уставы 1894 елның 17 мартында кабул ителә. Аңа нигезләнеп биш бүлек: Лихачев бүлеге, табигать-тарих, тарих-этнография, уку-укыту, сәнәгать бүлекләре, шулай ук





1917 елга кадәр эшләгән Музей советы ачыла. Музейның һәм һәрбер бүлекнең башында шәһәр думасы раслаган галимнәр директор булып торалар. Музей советының беренче рәисе (музей директоры) булып шәһәр башлыгы С. В. Дьяченко сайлана.

Музей җыелмасын төзүдә һәм аның бөтен эшчәнлегендә 1920 нче еллар гүзәл дәвер булып тора. Бу чорда музейга белгечләрнең яңа яшь буыны килә, аларның күпчелеге музей эшендә зур профессионаллар булып әверелә. Болар – профессор Б. Ф. Адлер, сәнгать белгечләре П. М. Дульский, П. Е. Корнилов, В. В. Егерев, танылган археолог һәм туган якны өйрәнүче Н. Ф. Калинин, тарихчылар К. С. Гобәйдуллин, М. С. Гобәйдуллина, М. Г. Худяков һ. б. Татар халкының мәдәниятен һәм көнкүрешен чагылдыручы материалларны туплау өчен Н. И. Воробьев белән берлектә музей хезмәткәрләре оештырган беренче археологик һәм этнографик экспедицияләр үткәрелә.

Музейның яшәү дәверендә аның исеме берничә тапкыр үзгәртелә: 1918 елдан – Губерна музее, 1921 елдан – АТССР (ТАССР) Үзәк музее, 1944 елдан – ТАССР Дәүләт музее, 1982 елдан – ТАССР Берләштерелгән дәүләт музее, 2001 елдан – Татарстан Республикасы Милли музее.

Музейның хәзерге фондларын 805400 саклау берәмлеге тәшкил итә һәм ул берничә эре фондтан һәм коллекциядән тора. Аның бай мирасы Татарстанның, шулай ук дөньяның борынгы халыклары тарихын, мәдәниятен, көнкүрешен, гореф-гадәтләрен чагылдыра. Алар палеолит чорыннан алып хәзерге көнгә кадәрге чыганаклар һәм материаллар төре буенча системалаштырылган.



Музей фондларын тулыландыру, саклау, реставрацияләү һәм яңарту, фәнни өйрәнү





буенча актив эш алып бара, яңа күргәзмәләр оештыра, үз байлыгын халыкка даими рәвештә тәкъдим итә.

Музей федераль әһәмияттәге архитектура һәм тарих һәйкәле булган элеккеге Казан Кунак йорты бинасында урнашкан.

Национальный музей Республики Татарстан – один из старейших и наиболее известных музеев России – крупнейшее хранилище памятников материальной и духовной культуры Среднего Поволжья и Приуралья.

Он основан в 1894 году как Казанский городской научно-промышленный музей, а его торжественное открытие состоялось 5 апреля 1895 года.

Основой музея стала частная коллекция А. Ф. Лихачева и экспонаты Казанской научно-промышленной выставки 1890 года. В первое десятилетие существования музея шло интенсивное формирование естественно-исторической и историко-этнографической коллекций. У истоков создания и формирования музейных экспонатов стояли видные учёные Казанского университета Н. Ф. Высоцкий, Н. П. Загоскин, Н. Ф. Катанов, А. А. Штукенберг и др. Активно пополняли фонды музея казанские коллекционеры и меценаты:

В. И. Заусайлов, О. С. Александрова-Гейнс, Г. Галеев (Баруди), Д. И. Образцов и др.

Устав музея был утвержден 17 марта 1894 года. В соответствии с ним были созданы пять отделов: лихачевский, естественно-исторический, историко-этнографический, учебный, промышленный, а также Совет музея (действовал до 1917 года). Во главе музея и каждого из отделов стояли директора из учёных, утверждённых городской думой. Первым председателем Совета музея (директором музея) был избран городской голова С. В. Дьяченко.

Замечательной эпохой в работе музея и формировании коллекций стали 1920-е годы. Пришло новое молодое поколение специалистов, многие из которых стали крупными музейными деятелями. Это профессор Б. Ф. Адлер, искусствоведы П. М. Дульский, П. Е. Корнилов, В. В. Егерев, известный краевед и археолог Н. Ф. Калинин, историки К. С. и М. С. Губайдуллины, М. Г. Худяков и др. Организуются первые археологические и этнографические экспедиции, предпринятые сотрудниками музея во главе с Н. И. Воробьёвым, по сбору материалов, отражающих культуру и быт татарского народа.

За годы существования музея неоднократно менялось его название: с 1918 года – Губернский музей, с 1921 года – Центральный музей АТССР (ТАССР), с 1944 года – Государственный музей ТАССР, с 1982 года – Государственный объединённый музей ТАССР, с 2001 года – Национальный музей Республики Татарстан.

Современные фонды музея насчитывают свыше 805 400 единиц хранения и состоят из нескольких крупных фондов и коллекций. Богатейшее наследие музея отражает историю, культуру, быт, традиции народов, живущих в Татарстане, а также древнейших мировых цивилизаций. Они систематизированы по типу источников и материалов от эпохи палеолита до наших дней.

Музей ведёт активную работу по комплектованию, хранению, реставрации, научному исследованию фондов, орга-



низует новые выставки, постоянно популяризируя свои раритеты.

Музей занимает здание бывшего казанского Гостиного двора, которое является памятником архитектуры и истории федерального значения.

*Укырга тәкъдим итәбез:*
*Советуем прочитать:*

**Татарстан музейлары** хәзинәләреннән = Сокровища музеев Татарстана /төз. А. Д. Хәйруллина һ. б. – Казань: Kazan-Казань, 1999. – 72 б. – Текст на татар. и рус. яз.

**Нәҗипова Г.** «Милли музей – Татарстанның бренды булырга тиеш» /әңгәмәдәш Л. Насыйхова //Татарстан. – 2015. – № 5. – Б. 68–70.

**Назипова Г. Р.** Казанский городской музей. Очерки истории 1895–1917 годов. – Казань: Kazan-Казань, 2000. – 272 с.

**Синицына К. Р.** Полвека музеев Казани и Татарии: очерки истории 1917– 1967 годов. – Казань: Kazan-Казань, 2002. – 280 с.

**Валеева Л. Г.** Страницы прошлого листая: из истории Государственного объединенного музея ТАССР 1970–1980 годов. – Казань: Kazan-Казань, 2005. – 368 с.

**Национальный музей** Республики Татарстан: [фотоальбом]. – Казань, 2014. – 95 с.: цв. ил.

**Наследие веков** = Гасырлар мирасы = Heritag e of the Ages: из собраний Гос. музея РТ. – Казань: Заман, 2000. – 160 с.: ил. – На рус., татар., англ. яз.

**Сокровища Республики Татарстан** = Татарстан Республикасы хәзинәләре /автор идеи, гл. ред., сост. Г. Р. Назипова. – Казань: ООО «Современная полиграфия», 2012. – 412 с.: цв. ил. – Текст парал. рус и татар. яз.

**Сокровища Республики Татарстан** = Treasures of Republik of Tatarstan /автор идеи, гл. ред., сост. Г. Р. Назипова. – Казань: ООО «Современная полиграфия», 2012. – 412 с.: цв. ил. – Текст парал. рус и англ. яз.





**15** май/мая



Нургаяз Салих улы Гарифҗанов
Нургаяз Салихович Гарифьянов
1920—1970

Туына 100 ел
100 лет со дня рождения

Күренекле физик, физика-математика фәннәре докторы, профессор Нургаяз Салих улы Гарифҗанов 1920 елның 15 маенда элекке Вятка губернасының Малмыж өязенә кергән (хәзер Татарстан Республикасы Балтач районы) Чутай авылында игенче гаиләсендә туа. 1928 елда аларның гаиләсе Киров өлкәсенең Малмыж шәһәренә күчеп килә. Нургаяз башлангыч белемне татар мәктәбендә ала, аннары Малмыж урта мәктәбендә укый.

1939 елда Н. Гарифҗанов Казан дәүләт университетының физика-математика факультетына укырга керә. 1942 елда аны Совет Армиясе сафларына алалар һәм ул элемтә взводы командиры булып Украина, Молдовия территориясендә барган сугышларда, Румыния, Венгрия, Болгарияне фашистлардан азат итүдә катнаша. Күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан соң Н. Гарифҗанов Казан университетында укуын дәвам итә. 1949 елда университетны тәмамлый, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы булган Казан физика-техника институтының аспирантурасына укырга керә һәм гомере буе шунда эшли. 1953 елда кандидатлык диссертациясен уңышлы яклый.

1966 елда Нургаяз Салих улы докторлык диссертациясен яклый. 1968 елдан ул – институтның электрон парамагнит резонанс лабораториясе мөдире. Биредә эшләү дәверендә ул яшь белгечләр, фәнни дәрәҗә алган галимнәр әзерли.

Магнитлы радиоспектроскопия юнәлешендәге фәнни тикшеренүләре Н. С. Гарифҗановка дөньякүләм танылу китерә. Ул – йөздән артык зур фәнни хезмәт авторы. Галим, теоретик булу белән беррәттән, киң колачлы экспериментатор да. Физик буларак ул комплекслы кушылмалар химиясенең күп тармакларын үстерү һәм киңәйтүгә зур өлеш кертә, физика фәненең иң актуаль юнәлешендә әйдәп баручы галим дәрәҗәсенә үсеп җитә.

1954 елда Н. С. Гарифҗанов СССР Фәннәр академиясе Президиумы премиясе лауреаты була. 1970 елда аңа ТАССРның атказанган фән эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә.

Нургаяз Салих улы Гарифҗанов 1970 елның 14 мартында вафат була.

Исемен мәңгеләштерү ниятеннән, ул укыган Малмыж урта мәктәбенә аның исеме бирелә. 1971 елдан Казан шәһәренең Таулар микрорайонындагы яңа бер урам профессор Н. С. Гарифҗанов исемен йөртә.

Видный учёный, доктор физико-математических наук, профессор Нургаяз Салихович Гарифьянов родился 15 мая 1920 года в деревне Чутай Малмыжского уезда Вятской губернии (ныне Балтасинский район Республики Татарстан) в семье крестьянина. В 1928 году семья переезжает в город Малмыж Кировской области. Начальное образование будущий физик получает в татарской школе, потом заканчивает Малмыжскую среднюю школу.

В 1939 году Н. Гарифьянов поступает на физико-математический факультет Казанского университета. В 1942 году его призывают в ряды Советской Армии. Командиром радиовзвода участвует в военных операциях на территории Украины, Молдавии, принимает участие в освобождении Румынии,





Венгрии, Болгарии. За боевые заслуги награждается орденом Красной Звезды и медалями.

После демобилизации из рядов Советской Армии Н. Гарифьянов продолжает учёбу в Казанском университете. Закончив университет в 1949 году, поступает в аспирантуру при Казанском физико-техническом институте Казанского филиала Академии наук СССР и в 1952 году успешно защищает кандидатскую диссертацию на тему «Парамагнитное поглощение в некоторых соединениях редкоземельных металлов».

В 1966 году Нургаяз Салихович защищает докторскую дисертацию. С 1968 года заведует лабораторией электронного парамагнитного резонанса в Казанском физико-техническом институте. За время работы в институте подготовил большое количество молодых учёных – кандидатов наук.

Мировое признание Н. С. Гарифьянову принесли исследования комплексных соединений элементов переходных групп и редкоземельных элементов без выделения их из растворов. Его перу принадлежат работы по парамагнитной релаксии. В общей сложности им написано сто научных работ по актуальным проблемам физики. В 1947 году учёный стал лауреатом премии Президиума Академии наук СССР. В 1970 году Н. С. Гарифьянову присвоено почётное звание заслуженного деятеля науки ТАССР.

Нургаяз Салихович Гарифьянов умер 14 марта 1970 года.

Малмыжская средняя школа, где он учился, сегодня носит его имя. С 1971 года одна из улиц города Казани носит имя профессора Н. С. Гарифьянова.

*Укырга тәкъдим итәбез:*
*Советуем прочитать:*

**Камалов А.** Заманыбызның атаклы тәҗрибәче физигы; Ильясов Ә. Укытучым турында истәлекләр //Мәшһүр татар галимнәре: мәкаләләр, истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – Б. 330–335; 335–337.

**Миңнуллин Г.** Профессор Гарифьянов урамы //Соц. Татарстан. – 1973. – 12 апр.

**Ганеева А., Парамонова Н.** Гарифьянов Нургаяз Салихович //Казанский университет (1804–2004): биобиблиогр. словарь. Т.2. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2004. – С. 297.

**Белокопытов В., Шевченко Н.** Их именами названы улицы Казани. – 2-е изд., испр. и доп. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1977. – 400 с. – Н. С. Гарифьянов. – С. 76–78.

**Амиров К. Ф.** Казанских улиц имена /К. Ф. Амиров, Р. Х. Ахметзянов, Р. Г. Вениаминов. – Казань: Центр информационных технологий, 2008. – 592 с. – Гарифьянова. – С. 126.

**Гудкова В.** Беззаветный труженик науки //Вечерняя Казань. – 1986. – 9 апр.



**4** июнь/июня



Лена Шагыйрьҗан
Лена Шагирзян
1945—2017

Тууына 75 ел
75 лет со дня рождения

Татарстан Республикасының халык шагыйрәсе Лена Галимҗан кызы Шакирҗанова (Лена Шагыйрьҗан) 1945 елның 4 июнендә Татарстан АССРның Актаныш районы Пучы авылында укытучы гаиләсендә туа. Күп тә үтми, аларның гаиләсе Әтнә районына күченә. Лененың балачагы һәм мәктәп еллары шушы районның Күлле Киме һәм Түбән Көек авылларында уза. 1962 елда Күлле Киме урта мәктәбен тәмамлагач та ул, Казанга килеп, Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. 1967 елда институтны тәмамлап, Казан шәһәренең 80 нче татар урта мәктәбендә бер ел укытучы булып эшли.

1968–1973 елларда ул Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә җырчы-артистка хезмәтендә була. Соңрак, 1974–1987 елларда, Татарстан дәүләт радиокомитетында тәрҗемәче-журналист булып эшли.

1987 елдан Л. Шагыйрьҗан – язучы-профессионал, фәкать әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Л. Шакирҗанованың беренче шигырьләре мәктәптә укыган елларында район газетасында һәм «Пионер» (хәзер «Ялкын») журналында басылалар. Студентлык елларында ул даими рәвештә әдәби чараларга йөри, күренекле язучылар,





шагыйрьләр белән очраша, үзенең иҗат стилен камилләштерү өстендә эшли, рус һәм татар әдәбияты классикларыннан өйрәнә.

1970 елда «Казан утлары» журналында шагыйрәнең укучылар тарафыннан җылы кабул ителгән бер төркем шигырьләре басыла. Шул вакыттан ул көндәлек матбугатта даими катнаша килә. Ленаның бер бәйләм шигырьләре 1977 елда «Кызлар җыры» исемле күмәк җыентыкка урнаштырыла. 1982 елда Татарстан китап нәшриятында «Яшь шагыйрьнең беренче китабы» сериясендә «Мөлдерәмә күңел» дигән мөстәкыйль шигъри җыентыгы басылып чыга. 1986 елда «Ышанам йөрәгемә» исемле икенче китабы дөнья күрә. Шушы беренче шигъри җыентыклары белән үк ул үзен романтик рухлы, нечкә хисле, хатын-кызларга гына хас үз язу манерасы, шигъри йөзе булган талантлы каләм иясе итеп таныта.

Л. Шагыйрьҗан ялкынлы публицистик язмалар, әдәбиятка кагылышлы теоретик һәм тәнкыйди мәкаләләр, С. Хәким, Р. Яхин, С. Садыйкова кебек атаклы өлкән буын иҗат әһелләре турындагы истәлек язмалары, замандашларына атап язган шигъри багышламалар авторы буларак та билгеле.




Л. Шагыйрьҗан – шигъри тәрҗемә остасы. Аның тәрҗемәсендә татар укучылары күренекле рус һәм чит ил шагыйрьләре – А. Пуш-





*Лена Шагыйрьҗан, Луара Шакирҗан, Шамил Закиров*

кин, Г. Державин, А. Ахматова, М. Цветаева, Г. Мистраль, Р. М. Рильке – иҗатыннан шигъри үрнәкләр белән танышалар. Борынгы төрки әдәбият җәүһәрләреннән XI йөз шагыйре Йосыф Баласагуниның «Котадгу белег» («Игелекле белем») исемле поэмасыннан зур бер бүлек Л. Шагыйрьҗан тәрҗемәсендә «Мәдәни җомга» газетасында һәм «Мирас» журналында дөнья күрә.

Л. Г. Шакирҗанова – Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе. Татарстан китап нәшриятында басылган «Божра вә Хөҗрә: шигырьләр, поэмалар» (2002), «Сагынмалык: истәлекләр, багышламалар» (2005) җыентыклары өчен 2011 елда Г. Тукай премиясенә ия була. 2016 елда татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык иҗади эшчәнлеге өчен аңа Татарстан Республикасының халык шагыйрәсе исеме бирелә.

Лена Галимҗан кызы Шакирҗанова 2017 елның 16 гыйнварында Казанда вафат була. Татарстан Республикасының Әтнә районы Күлле Киме авылы зиратында җирләнә.

Народная поэтесса Республики Татарстан Лена Галимзяновна Шакирзянова (Лена Шагирзян) родилась 4 июня 1945 года в деревне Поисево Актанышского района Татарской АССР в семье сельских учителей. Вскоре семья переезжает в






Атнинский район. Детские и школьные годы Лены проходят в деревнях Кулле-Киме и Нижний Куюк (Түбән Көек). В 1962 году после окончания Кулле-Кименской средней школы она поступает учиться на историко-филологический факультет Казанского государственного педагогического института. После окончания института в 1967 году один год преподает литературу в школе № 80 города Казани.

В 1968–1973 годах поет в Татарском государственном ансамбле песни и танца. В 1974–1987 годах работает журналистом-переводчиком в Татарском государственном радиокомитете.

С 1987 года Л. Шагирзян начинает профессиональную литературную деятельность, целиком посвящает себя поэтическому творчеству.

Лена Шакирзянова сочинять стихи начинает ещё в школьные годы. Первые стихи были опубликованы в районной газете и на страницах детского журнала «Пионер» (ныне «Ялкын»). В годы студенчества она регулярно посещает литературные мероприятия, встречается с маститыми писателями и поэтами, работает над совершенствованием своего поэтического стиля, учится у классиков русской и татарской литературы.




В 1970 году в журнале «Казан утлары» был опубликован первый цикл её стихотворений, тепло встреченный читателями. С этого времени её имя не сходит со страниц республиканских газет и журналов.








В 1977 году большая подборка её стихов была помещена в коллективном сборнике «Кызлар жыры» («Песня девушек»), а в 1982 году она издает свой авторский сборник «Мөлдерәмә күңел» («Душа переполненная») в серии «Яшь шагыйрьнең беренче китабы» («Первая книга молодого поэта». В 1986 году выходит в свет вторая книга «Ышанам йөрәгемә» («Верю сердцу»). Поэзия Л. Шагирзян имеет лирико-публицистический характер, тематика её произведений разнообразна. Стихам Л. Шагирзян присущи особая мелодичность, певучесть, национальный колорит.

Она известна как автор пламенных публицистических заметок, литературно-критических статей, воспоминаний о выдающихся представителях татарского народа – С. Хакиме, Р. Яхине, С. Садыковой, поэтических посвящений современникам.

Лена Шагирзян – мастер литературного перевода. В её переводе на татарский язык увидели свет произведения известных русских и зарубежных поэтов, таких как А. Пушкин, Г. Державин, А. Ахматова, М. Цветаева, Г. Мистраль, Р. М. Рильке. Из памятников древней тюркской литературы ею был осуществлен перевод фрагмента сочинения поэта XI века Юсуфа Баласагуни «Кутадгу билиг» («Благодатное знание»), опубликованный в газете «Мәдәни җомга» и журнале «Мирас».

Л. Г. Шакирзянова – заслуженный деятель искусств Республики Татарстан. В 2011 году за книги «Божра вэ Хожрэ» («Круговорот», 2002) и «Сагынмалык» («Дарю на память», 2005), изданных в Татарском книжном издательстве, ей была присуждена Государственная премия Татарстана им. Г. Тукая. В 2016 году за вклад в татарскую литературу и многолетнюю плодотворную творческую деятельность Л. Шакирзяновой



присвоено звание народной поэтессы Республики Татарстан.

Лена Галимзяновна Шакирзянова скончалась 16 января 2017 года в Казани. Похоронена в кладбище села Кулле-Киме Атнинского района Республики Татарстан.

*Укырга тәкъдим итәбез:*
*Советуем прочитать:*

**Шагыйрьҗан Л.** Мөлдерәмә күңел: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 79 б.

**Шагыйрьҗан Л.** Ышанам йөрәгемә: шигырьләр, поэма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 80 б.

**Шагыйрьҗан Л.** Иман әлифбасы: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 159 б.

**Шагыйрьҗан Л.** Шигырьләр, поэма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 208 б.

**Шагыйрьҗан Л.** Канатлы ат: балалар өчен шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 40 б.

**Шагыйрьҗан Л.** Божра вә Хөҗрә: шигырьләр һәм поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 368 б.

**Шагыйрьҗан Л.** Сагынмалык: истәлекләр, багышламалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 303 б.

**Шагыйрьҗан Л.** Хуш исләре җиһан гөлләренең: поэма, эссе, лирик-фәлсәфи миниатюралар, тәрҗемәләр, мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 303 б.

**Шагыйрьҗан Л.** Кәрәз төбе каты бал…: шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 271 б.

**Шагыйрьҗан Л.** Алла ярдәм бирсен сезгә, кешеләр!: шигырьләр, мөнәҗәтләр. – Казан: Ак бүре, 2017. – 67 б.

**Шакирзянова Л.** Стихи: пер. с татар. //Современная татарская поэзия. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. – С. 421–431.

**Даутов Р. Н., Нуруллина Н. Б.** Совет Татарстаны язучылары: биобиблиогр. белешмәлек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 639 б. – Лена Шакирҗанова. – Б. 545.





**Әдипләребез**: биобиблиогр. белешмәлек. 2 томда. Т.2 / [төз. Р. Н. Даутов, Р. Ф. Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 735 б. – Лена Шагыйрьҗан. – Б. 632–633.

**Даутов Р.** Балачак әдипләре: биобиблиогр. белешмәлек. 2 кит. = Писатели нашего детства: биобиблиогр. спр. Кн. 2. – Казан: Мәгариф, 2004. – 286 б. – Лена Шагыйрьҗан. – Б. 260–270. – Текст татар һәм рус телләрендә.

**Галиуллин Т.** Егетлеккә ирешкән шагыйрә //Мәдәни җомга. – 2011. – 15 апр. – Б. 11.

**Рахмани Р.** Шагыйрәнең язмыш келәме //Казан утлары. – 2003. – № 4. – Б. 121–134; Хәзерге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 247–250.

**Вәлиулла И.** Һәр шагыйрь – бер дәрья…: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 208 б. – «Безгә бер Хәбәр кирәк» (Лена Шагыйрьҗан иҗатында бүгенге кешелек җәмгыятенең кыен хәле – кризисы турында уйланулар). – Б. 94–113.

**Зәйнашева Г.** Һәр җөмләсе – энҗе-мәрҗән //Шәһри Казан. – 2004. – 17 апр.

**Гаташ Р.** Без ирешкән ак бәхет //Ватаным Татарстан. – 2011. – 12 апр. – Б. 5.

**Гыйльманов Г.** Шагыйрьҗан вакыты //Шәһри Казан. – 2011. – 12 апр. – Б. 9.

**Хуҗахмәт Ф.** Иман китерергә вакыт җиткән һәммәбезгә //Ватаным Татарстан. – 2014. – 24 гыйн. – Б. 3.

**25** июнь/июня

Татарстан Автономияле
Совет Социалистик Республикасы
Татарская Автономная
Советская Социалистическая
Республика
1920

Төзелүенә 100 ел
100 лет со дня образования

Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорыннан алып Идел һәм Чулман елгалары арасы татар халкының тарихи җирлеге буларак кабул ителә. Күп гасырлар дәвамында безнең ата-бабаларыбыз, башка халык вәкилләре белән берлектә, мөстәкыйль тормыш алып баралар, үзләренең уникаль рухи һәм матди мәдәниятләрен үстерәләр.

XX гасырга татар халкы тулысынча формалашкан милләт булып килеп керә. 1913 елга Казан губернасында 200 дән артык сәнәгать предприятиесе санала. Мәгариф, китап бастыру эше, әдәбият һәм сәнгать, милли театр үсеше буенча татарлар Россия халыклары арасында төп урыннарны алып торалар.



*«Биш ел эчендә» китабы*

Февраль революциясе илдә демократик үзгәрешләр башлануга этәргеч була. Милли интеллигенция арасында татарларның дәүләтчелеген яңадан торгызу проектлары буенча актив фикер алышулар бара.




1917 елның май аенда I нче Бөтенроссия мөселманнары корылтаенда реформатор көчләр берләшә, Бөтенроссия мөселманнарының вакытлы советы (Шура) төзелә, эчке Россия мөселманнарының штатын булдыру фикере тарала.

Аны тормышка ашыру өчен Уфада эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Милләт мәҗлесе чакырыла, территориаль автономия – Идел-Урал штаты – оештыру турындагы мәсьәлә карала. Идел-Урал штатын II Бөтенроссия мөселман гаскәриләре корылтае карары буларак игълан итәргә уйланыла. Биредә сүз халыкның ирекле, үзләре теләгән, «өстән» декрет буенча түгел, демократик юл белән идарә ителүче күпмилләтле дәүләтен төзү турында бара.

Ләкин 1918 елның 22 мартында Советларның Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты (ВЦИК) Татар-Башкорт Совет республикасы турында Нигезләмә кабул итә. Асылда бу Идел-Урал штатының большевиклар тәкъдим иткән варианты була. Соңрак Татар республикасы төзү буенча тагын берничә вариант барлыкка килә. Туган вазгыять нәтиҗәсендә, 1920 елның маенда РСФСРның Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы тарафыннан Татарстан Автономияле республикасы турында Декрет әзерләнә. Декрет нигезендә РСФСР составында Татарстан АССР оештырыла. Аңа элеккеге Казан губернасының күпчелек өязләре, Сембер, Самара, Уфа, Вятка губерналарының бер-




*ТАССР Конституциясе. 1937 ел*



ничә өязе һәм аерым волостьлары кертелә. Үзәге итеп, әлбәттә, Казан шәһәре тәгаенләнә.




1920 елның 25 июнендә Казан губерна Башкарма Комитеты хакимиятне тантаналы рәвештә ТАССР ревкомына тапшыра. Шул вакыттан бирле бу дата Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы игълан ителгән көн буларак билгеләп үтелә.

1920 елның сентябрь ахырында ТАССРның Үзәк Башкарма Комитеты сайлана, аннары хөкүмәт – Халык Комиссарлары Советы төзелә. Үзәк Башкарма Комитет рәисе итеп Б. Мансуров, хөкүмәт башлыгы итеп С. Сәетгалиев сайлана. Яшь республика тормышының төрле тармакларына җитәкчелек итү вазыйфалары эчке эшләр, юстиция, мәгариф, сәламәтлек саклау, социаль тәэминат, җир эшләре, азык-төлек һәм финанс комиссариатларына йөкләнә.

Шулай итеп, Гражданнар сугышы елларында автономияле республика – ТАССР – сыйфатында татар халкының дәүләтчелеге төзелә. Республика үзенең шушы статусын 1990 елның августына кадәр саклый.




Со времён Болгарского государства, Золотой Орды и Казанского ханства междуречье Волги и Камы традиционно являлось исторической территорией татарского народа. На протяжении многих столетий его предки вместе с представителями других этносов развивали самобытный уклад жизни, уникальную духовную и материальную культуры.

В XX век татарский народ вступает как вполне сформировавшаяся






нация. К 1913 году в Казанской губернии насчитываются более 200 промышленных предприятий. По уровню просвещения, книгоиздательского дела, развития литературы и искусства, национального театра татары занимают ведущие позиции среди народов Российской империи.

Февральская революция ознаменовала начало демократических перемен в стране. В среде национальной интеллигенции начинают активно обсуждаться проекты восстановления государственности татар. В мае 1917 года на I-ом Всероссийском мусульманском съезде происходит объединение реформаторских сил, создается Временный Всероссийский мусульманский совет (Шуро), получает распространение идея создания штата мусульман внутренней России.

Для её реализации в Уфе было созвано Национальное собрание мусульман внутренней России и Сибири, где был поставлен вопрос об учреждении территориальной автономии – Волжско-Уральского штата (Идел-Урал штаты). Предполагалось, что штат будет провозглашен решением II Всероссийского съезда воинов-мусульман. Речь шла об образовании через свободное волеизъявление народов, а не по декрету «сверху» многонационального государства с демократической формой правления.

Однако 22 марта 1918 года ВЦИК Советов принимает Положение о Татаро-Башкирской Советской республике. По существу, это был большевистский вариант Волжско-Уральского штата. Позднее появилось ещё несколько вариантов создания Татарской республики. Итогом сложившейся ситуации стал Декрет ВЦИК и СНК РСФСР от 27 мая 1920 года об образовании Татарской автономии. Татарская АССР была образована в составе Российской Федеративной Республики. Она



включала территории большой части Казанской губернии, а также несколько уездов и волостей Симбирской, Самарской, Уфимской и Вятской губерний. 25 июня 1920 года Казанский губисполком в торжественной обстановке передал власть Ревкому ТАССР. С тех пор эта дата считается официальным днём провозглашения Татарской Автономной Советской Социалистической Республики.

В конце сентября 1920 года был избран Центральный Исполнительный Комитет, затем образовано правительство – Совет Народных Комиссаров. Председателем ЦИК избрали Б. Мансурова, главой Правительства – С. Саид-Галиева. Задачи управления некоторыми сферами жизни молодой республики были возложены на наркоматы внутренних дел, юстиции, просвещения, здравоохранения, социального обеспечения, земледелия, продовольствия и финансов.

В годы Гражданской войны была создана государственность татарского народа в форме автономной республики – ТАССР, удовлетворившая некоторые его чаяния. Такой статус республика сохраняла до августа 1990 года.

*Укырга тәкъдим итәбез:*
*Советуем прочитать:*

**Татарстан АССР** тарихы: (иң борынгы заманнардан алып безнең көннәргә кадәр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. – 744 б.

**Таһиров И.** Гасырлар чатында. – Казан: Мастер-Лайн, 1998. – 474 б.

**Дәүләт Н.** 1917 Октябрь инкыйлабы вә төрк-татар Милләт Мәҗлесе (эчке Русия вә Себер мөселманнарының Милләт Мәҗлесе. 1917–1919). – Казан: Җыен: Милли китап, 2008. – 384 б.

**Мөхәммәтшин Ф.** Өченче меңьеллык чигендә Татарстанның тарихи потенциалы //Ватаным Татарстан. – 2000. – 24 июнь.

**Таһиров И.** Милләтара хәлләр һәм дәүләт идарәсе: Татарстан мәмләкәте. Татарстан. 1920 еллар //Мирас. – 1996. – № 7-8. – Б.209–212.





**Таһиров И.** Идел-Урал штаты //Мирас. – 2004. – № 8. – Б.103–107.

**100-летие образования** Татарской АССР: сб. док. и материалов. В 3 т. Т.1 /авт. — сост. З. С. Миннуллин. – Казань: Заман, 2017. – 520 с.

**Образование Татарской АССР**: сб. док. и материалов / под ред. И. М. Климова и М. К. Мухарямова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1963. – 502 с.

**Татарская АССР**: история создания (1917–1920) = Татарстан АССР: оешу тарихы (1917–1920) = Tatar ASSR: History of Establishment (1917–1920) /авт. — сост. З. С. Миннуллин. – Казань: Заман, 1917. – 208 с.

**Республика Татарстан**: история и современность /М. С. Гатин [и др.]; [рук. проекта, координатор Л. З. Миннуллина]. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2018. – 213 с.: фотоил.

**Центральные органы** государственной власти и управления Татарстана (1920–2010 гг.): научно-справочное издание /Р. В. Шайдуллин [и др.]; Ин-т татар. энцикл. АН РТ. – Казань: [Ин-т Татар. энциклопедии]: [Изд-во МОиН РТ], 2010. – 311 с.: ил., портр., гербы

**Султан-Галиев М.** Избранные труды = Сайланма хезмәтләр. – Казань: Гасыр, 1998. – 720 с., 16 л. ил.

**Тагиров И. Р.** История национальной государственности татарского народа и Татарстана. – 2-е изд. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. – 455 с.

**Тагиров И. Р.** На изломе истории. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. – 423 с.

**Давлетшин Т.** Советский Татарстан: теория и практика ленинской национальной политики. – Казань: Джиен, 2005. – 485 с.

**Хайрутдинов Р. Г.** Осуществление Коммунистической партией ленинской программы по национальному вопросу в 1917–1920 гг. (по материалам Поволжья и Приуралья). – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1976. – 246 с.

**Шигабиев И.** Из истории образования ТАССР //Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2005. – № 1. – С. 101–110.



**8** июль/июля



Җәвад Тәрҗеманов
Джавад Тарджеманов
1920—1995

Тууына 100 ел
100 лет со дня рождения

Язучы, галим Җәвад Әфтах улы Тәрҗеманов 1920 елның 8 июлендә Казан шәһәрендә дин эшлеклесе гаиләсендә туа. 1938 елда Яңа бистәдәге 13 нче санлы татар урта мәктәбен тәмамлагач, Казан химия-технология институтының механика факультетына укырга керә. Бөек Ватан сугышы елларында, институтта уку белән бергә, хәрби заводта эшли.

1944 елда диплом яклап, институтта аспирантурага калдырыла һәм бер үк вакытта заводта инженер-технолог булып эшли. 1950 елда ул техник фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен диссертация яклый һәм аннан соң үзе укыган Казан химия-технология институтында доцент булып эшли, институтта чыгарылган «Гыйльми язмалар» басмасының җаваплы секретаре һәм редакторы вазифаларын башкара. Аның үз белгечлеге буенча дистәләгән хезмәтләре бар. Җәвад Әфтах улына 1981 елда Татарстан АССРның атказанган фән һәм техника эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә.

Ж. Тәрҗеманов әдәбиятка мәктәптә укыган вакытында ук килә. «Безнең җавап» исемле шигыре җиденче сыйныфта укыганда язылып, 1935 елда «Яшь ленинчы» газетасында басылып чыга. 1938 елда аның «Галстук» исемле беренче шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.





*Татар әдипләре Чыңгыз Айтматов белән Казан университеты каршында*

Прозада язучы кыска хикәяләре белән танылa. Аның «Ябалак һәм тавык», «Шаян белән Наян», «Көмешкойрык» кебек әкиятләре зур популярлык казана; «Шуктуган» исемле фәнни-популяр әкияте берничә телгә (инглиз, испан, гарәп һ. б.) тәрҗемә ителеп басылып чыга.

1960 нчы еллардан башлап Ж. Тәрҗеманов яшьләр һәм өлкәннәр өчен дә яза. 1965 елда аның бөек математик Н. И. Лобачевскийның тормышы һәм фәндәге тәүге адымнары турында «Лобачевскийның яшьлеге» («Юность Лобачевского»), соңрак «Көмеш дага» (беренчесенең эшкәртелгән яңа варианты) исемле документаль романнары басылып чыга.




Ж. Тәрҗеманов публицистика, очерк, әдәби-тәнкыйть һәм балалар драматургиясе өлкәсендә дә актив эшли.

Җәвад Тәрҗеманов 1995 елның 9 мартында Казан шәһәрендә вафат була.






Писатель, учёный Джавад Афтахович Тарджеманов родился 8 июля 1920 года в Казани в семье религиозного деятеля. Окончив татарскую среднюю школу № 13 в Новотатарской Слободе, он поступает на механический факультет Казанского химико-технологического института. В годы Великой Отечественной войны учебу в институте совмещает с работой на военном заводе.

В 1944 году после защиты диплома Д. Тарджеманов продолжает обучение в аспирантуре, одновременно работает инженером-технологом на заводе. В 1950 году защищает диссертацию на соискание учёной степени кандидата технических наук. В родном институте работает доцентом, одновременно – ответственным секретарем и редактором издания «Научные труды КХТИ им. С. М. Кирова». Является автором десятка научных работ по специальности. В 1981 году Д. Тарджеманову присвоено почётное звание заслуженного деятеля науки и техники Татарской АССР.

Д. Тарджеманов приходит в литературу еще в школьные годы. Стихотворение «Безнең җавап» («Наш ответ») было написано учеником седьмого класса и опубликовано в 1935 году в газете «Яшь ленинчы». Первый сборник его стихов «Галстук» увидел свет в 1938 году.

В прозе писатель известен короткими рассказами и сказками: «Ябалак белән тавык» («Сова и курица»), «Шаян белән Наян» («Озорники»), «Көмешкойрык» («Серебряный хвостик»), его научно-популярная сказка «Шуктуган» была переведена английский, испанский, арабский и другие языки.

С 1960 года Д. Тарджеманов пишет для молодёжи и взрослых. В 1965 году издается его документальный роман, посвящённый жизни и творчеству великого учёного-математика, «Юность Лобачевского», который впоследствии был пе-




реработан и издан под названием «Көмеш дага» («Серебряная подкова»).

Д. Тарджеманов активно работал в области публицистики, очерка, литературной критики и детской драматургии.

Джавад Афтахович Тарджеманов скончался 9 марта 1995 года в городе Казани.

*Укырга тәкъдим итәбез:*
*Советуем прочитать:*


**Тәрҗеманов Җ.** Сайланма әсәрләр /кереш сүз авт. Н. Гыйззәтуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. – 371 б.

**Тәрҗеманов Җ.** Көмеш дага: тарихи роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. – 452 б.

**Тәрҗеманов Җ.** Ачкыч һәм баскыч: сайланма шигырьләр, хикәяләр, пьесалар, мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 367 б.

**Тәрҗеманов Җ.** Лобачевскийның яшьлеге: докум. роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 342 б.

**Тәрҗеманов Җ.** Очрашулар, очрашулар: хикәяләр, очерклар, юлъязмалар, истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 368 б.

**Тәрҗеманов Җ.** Балачак сабаклары: балалар өчен гыйбрәтле хикәяләр, әкият-пьеса. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. – 63 б.

**Тәрҗеманов Җ.** Әкиятләр: кече яшьтәге мәктәп балаларына. – Казан, 2000. – 44 б.

**Тәрҗеманов Җ. И.** онытылмас Бишбалта!: язучының балачагы //Казан. – 1996. – № 3–4. – Б. 89–95.

**Тәрҗеманов Җ.** Ахирәт дустым турында баллада: документаль композиция-либретто //Ялкын. – 1995. – № 4. – Б. 6–11, № 5. – Б. 2–6.

**Тарджеманов Д.** Юность Лобачевского: докум. роман: пер. с татар. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1965. – 302 с.

**Тарджеманов Д.** Юность Лобачевского: докум. роман: пер. с татар. – 2-ое изд. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1968. – 302 с.




**Тарджеманов Д.** Шуктуган: сказка /пер. с татар. Г. Снегирева. – М.: Дет. лит., 1970. – 17 с.

**Тарджеманов Д.** Серебряная подкова: роман. – М.: Сов. писатель, 1979. – 416 с.

**Тарджеманов Д.** Шуктуган: сказка /пер. с татар. Г. Снегирева. – 2-ое изд. – М.: Дет. лит., 1982. – 17 с.

**Тарджеманов Д.** Сказки. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. – 43 с.

**Тарджеманов Д.** Свет желтых акаций: семейный альбом: Казань. Новая Слобода. Здесь прошли детские годы у автора // Казань. – 1995. – № 9–10. – С. 74–79.

**Әдипләребез**: биобиблиогр. белешмәлек. 2 томда. Т.2. [төз. Р. Н. Даутов, Р. Ф. Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 735 б. – Җәвад Тәрҗеманов. – Б. 424–426.

**Даутов Р. Н., Нуруллина Н. Б.** Совет Татарстаны язучылары: биобиблиогр. белешмә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 639 б. – Җәвад Тәрҗеманов. – Б. 457–460.

**Бәйрәмова Г.** Җәвад Тәрҗемановның тууына 80 ел //Казан утлары. – 2000. – № 7. – Б. 187–188.

**Ихсанова Л.** Ир кешенең өч гамәле //Ватаным Татарстан. – 2000. – 8 июль.

**Дәрзаман Ж.** Остаз // Шәһри Казан. – 2000. – 28 июль.

**Мияссәрова И.** Җәвад Тәрҗеманов (1920–1995) //Мәгариф. – 2004. – № 4. – Б. 51.

**Гиниятуллина А.** Писатели Советского Татарстана: биобиблиогр. спр. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. – 511 с. – Джавад Тарджеманов. – С. 393–395.



**9** сентябрь/ сентября



Казан сынлы сәнгать училищесы
Казанское художественное училище
1895

Ачылуына 125 ел
125 лет со дня открытия

Н. И. Фешин исемендәге Казан сынлы сәнгать училищесы – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы урта махсус һөнәри белем бирүче дәүләт мохтариятле (үзидарәле) белем бирү оешмасы.

Ул 1895 елның 9 сентябрендә Казан сынлы сәнгать мәктәбе буларак ачыла. Мәктәпне ачуда Петербургта сынлы сәнгать академиясен тәмамлаган Н. Н. Белькович, Х. Н. Скорняков, Г. А. Медведев, Ю. И. Тиссен, А. И. Денисов (соңыннан мәктәпнең беренче рәсем укытучылары) башлап йөри. Мәктәп Россия сынлы сәнгать академиясенә караган беренче урта һөнәри белем бирү йорты була. Демократик принциплар, кызыклы укыту программалары, югары квалификацияле педагоглар – болар барысы да бу уку йортының дәрәҗәсен күтәрә.

1920 нче еллар дәвамында бер-бер артлы үзгәртеп оештырулар булып тора. Казан сынлы сәнгать мәктәбе 1918 елда Казан дәүләт ирекле сынлы сәнгать остаханәләре (соңрак Казан дәүләт югары сынлы сәнгать-техник остаханәләре) итеп үзгәртелә; 1921 елда Казан сынлы сәнгать-техник институты; 1923 елда – Казан сынлы сәнгать техникумы; 1924 тә – Казан архитектура-сынлы сәнгать остаханәләре (техникум); 1926 елда Казан сынлы сәнгать-педагогия техникумы; 1927 елда



Казан театр техникумы белән берләштерелә, Казан берләштерелгән сынлы сәнгать-театр техникумы исеме ала; 1930 да – Татар сәнгатьләр техникумы; 1935 елда Татар сәнгатьләр техникумыннан аерылып чыга, Татар сынлы сәнгать техникумы, соңрак Казан сынлы сәнгать училищесы дип атала һәм хәзерге көнгә кадәр шушы исем белән йөри. 2006 елда Казан сынлы сәнгать училищесына Н. И. Фешин исеме бирелә. Ни өчен дигәндә, әлеге мәшһүр сәнгатькяр Казан сынлы сәнгать мәктәбен, аннары Петербург сынлы сәнгать академиясен тәмамлап Казанга, туган мәктәбенә укытучы булып кайта һәм анда 1923 елга кадәр эшли.

Дистәләрчә еллар дәвамында училище берничә буын талантлы рәссамнарны үзендә укытып, үстереп чыгарды.

Хәзерге вакытта Казан сынлы сәнгать училищесы биш бүлектә дүрт юнәлеш буенча белем бирә. Хәзерлек бүлеге – абитуриентлар әзерләү өчен махсус курслар – 1995 елда ачыла. Рәсем сәнгате (нәкышь) бүлеге, иң элеккеләрдән булып, рәссамнар һәм сәнгать мәктәпләре өчен рәссам-педагоглар әзерли. Дизайн бүлегендә житештерү-эшкуарлык өлкәсенә юнәлтелә торган дизайнерлар укый. Скульптура (сынлы сәнгать) бүлеге Казан сәнгать мәктәбендә элек тә була, 2001 елда яңадан ачыла. Сынчылар, сынчы-укытучылар әзерли. Гамәли-бизәлеш сәнгате һәм халык һөнәрчелеге бүлеге 2000 елда ачыла һәм шушы өлкәдә эшләячәк рәссам-бизәүче сәнгать осталары әзерли.

2008 елда Татарстан Мәдәният министрлыгы карары белән Яшел Үзән шәһәрендә Казан сынлы сәнгать училищесының филиалы ачыла.

Казан сынлы сәнгать училищесы Идел буенда сәнгать белеме бирү үзәгенә әверелә, сәнгать уку йортлары өчен методик база булып тора. Училище җирлегендә зона сәнгать күргәзмәләре һәм конференцияләр үткәрелә.

Казан сынлы сәнгать училищесы составына ике уку бинасы керә. Бу биналар – мәдәни мирас объектлары, федераль (бөтенроссия) әһәмиятле шәһәр төзелеше һәм архитектура һәйкәлләре. Мөштәри урамындагы 16 йортта урнашкан бина –







Осокин йорты, 1849 елда чиновник һәм алпавыт А. Г. Осокин (1818–1887) өчен архитектор И. П. Бессонов тарафыннан, соңгы чор провинциаль классицизм стилендә салынган. Училище бу бинага 1930 нчы елларда урнаша.

К. Маркс урамындагы 70 йортта урнашкан бина псевдорус стилендә 1900–1905 елларда архитектор К. Л. Мюфке (үзе мәктәптә укыта да) тарафыннан махсус сынлы сәнгать мәктәбе өчен төзелә. Училище биредә 1926 елга кадәр була. 2004 елда бу бина Казан сынлы сәнгать училищесына кайтарып бирелә. Аның рәсеме училище эмблемасында урнаштырылган.

Казанское художественное училище имени Н. И. Фешина – государственное автономное образовательное учреждение среднего профессионального образования Министерства культуры Республики Татарстан.

Училище было открыто 9 сентября 1895 года как Казанская художественная школа. Инициаторами её создания выступили выпускники Петербургской Академии художеств – Н. Н. Белькович, Х. Н. Скорняков, Г. А. Медведев, Ю. И. Тиссен, А. И. Денисов (позже они были первыми преподавателями рисунка и живописи этой школы). Эта была первая школа в системе средних специальных художественных учебных за-



ведений, подведомственных Академии художеств. Демократические принципы, интересные программы, высококвалифицированные педагоги способствовали популярности учебного заведения.

На протяжении 1920-х годов реорганизации следовали одна за другой. В 1918 году Казанская художественная школа была преобразована в Казанские свободные художественные мастерские (позднее – Казанские государственные высшие художественно-технические мастерские); в 1921 году – в Казанский художественно-технический институт, в 1923 году – в Казанский художественный техникум; в 1924 – в Архитектурно-художественный техникум; в 1926 – в Казанский художественно-педагогический техникум; в 1930 – в Татарский техникум искусств, в 1935 году – Татарский художественный техникум, позднее переименованный в Казанское художественное училище. В 2006 году Казанскому художественному училищу присвоено имя Н. И. Фешина, одного из первых его выпускников. В 1909 году, после окончания Петербургской Академии художеств, Николай Иванович возвращается в качестве преподавателя в Казань, в родную художественную школу.

В течение нескольких десятков лет из стен училища выходят многие поколения талантливых художников.

Сегодня Казанское художественное училище ведёт подготовку по четырем направлениям, действуют пять отделений. Подготовительное отделение – специальные курсы для подготовки абитуриентов – были открыты в 1995 году. Старейшее отделение живописи готовит художников и художников-педагогов для художественных школ. Отделение дизайна готовит специалистов для производственно-предпринимательской сферы. Отделение скульптуры, существовавшее еще в Казанской художественной школе, было вновь открыто в 2001 году, готовит скульпторов-преподавателей. Отделение декоративно-прикладного искусства и народных промыслов открыто в 2000 году для подготовки художников-мастеров в области декоративно-прикладного искусства.





По решению Министерства культуры Республики Татарстан в 2008 году в Зеленодольске открылся филиал Казанского художественного училища.

Казанское художественное училище является базовым училищем Поволжской методической зоны художественных училищ и училищ искусств. На базе училища проводятся зональные художественные выставки и конференции.

Казанское художественное училище расположено в двух учебных зданиях, являющихся объектами культурного наследия, памятниками градостроительства и архитектуры федерального (общероссийского) значения. Дом Осокина на улице Муштари, 16 выстроен в стиле позднего провинциального классицизма в 1849 году по проекту архитектора И. П. Бессонова для помещика А. Г. Осокина (1818–1887), училище размещается в нём с 1930-х годов.

Здание на улице Карла Маркса, 70 построено в псевдорусском стиле в 1900–1905 годах по проекту архитектора К. Л. Мюфке (который преподавал в школе) специально для художественной школы. Училище размещалось в нем до 1926 года. В 2004 году здание было вновь передано Казанскому художественному училищу. Изображение здания помещено на эмблеме училища.

*Укырга тәкъдим итәбез:*
*Советуем прочитать:*

**Урманче Б.** Казан сәнгать мәктәбе: заман һәм кешеләр // Казан утлары. – 1993. – № 3. – Б. 169–180.

**Бишбалта Н.** Сәнгать училищесында татарча укыйлар // Шәһри Казан. – 2018. – 2 окт. – Б. 6.

**Ключевская Е. П**. Казанская художественная школа. 1895–1917. – СПб.: Славия, 2009. – 239 с.

**Гильмутдинова О. А.** Обучение художников из татар в Казанском художественном училище в 1920–1940-е годы // Творчество Б. Урманче и актуальные проблемы национально-



го искусства: материалы Междунар. науч. — практ. конф. – Казань, 2012. – С. 362–367.

**Ключевская Е. П.** Из истории Казанской художественной школы (1897–1917) //Проблема развития русского искусства: темат. сб. науч. тр. / Ин-т живописи, скульптуры и архитектуры им. Репина. – 1985. – Вып. 18. – С. 65–73.

**Сотонина Г. И.** Воспоминания о 20-х годах Казанской художественной школы // Советское искусство 20-30-х годов. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1992. – С. 204–207.

**Кривошеева Т. Н.** Скульптура Татарстана: истоки, становление, традиции. – Казань: Отечество, 2013. – 256 с.; илл.

**Вагапов М.** Возрождение традиций; Даричева Е. «Содействовать художественному развитию…»; Кривошеева Т. Н. Первые шаги ваятелей //Казань. – 2006. – № 8–9. – С. 179–191; С. 191–197; С. 198–205.

**Зямилова А.** Возвращение к корням //Идель. – 2007. – № 10. – С. 76–78.

**Мамаева Т.** Новоселье в старом доме // Время и деньги. – 2005. – 9 сент.

**Червонная С. М.** ТатЛЕФ и творческие лаборатории экспрессионизма в Казанской художественной школе 1920-х годов //Русский авангард 1910–1920-х годов и проблемы экспрессионизма. – М.: Наука, 2003. – С. 531–566.





**10** сентябрь/ сентября



Мөхәммәдсадыйк Иманколый
Мухаммадсадык Иманкулый
1870—1932

Тууына 150 ел
150 лет со дня рождения

Дин эшлеклесе, шагыйрь Мөхәммәдсадыйк Шаһиәхмәт улы Иманколый 1870 елның 10 сентябрендә Казанда мулла гаиләсендә туа. Мөхәммәдсадыйкның бала чагы Яңа Бистәдә уза. Сигез яшьтә ятим кала. Ул башта Казан мәдрәсәләрендә белем ала.

1886 елда М. Иманколый Бохарага укуын дәвам итәргә китә. Биредә сигез ел белем ала.

1894 елда ул Казанга кайта һәм Яңа бистәдәге алтынчы мәчеткә икенче имам итеп билгеләнә. Биредә ул имам булып 1932 елга кадәр хезмәт итә.

1919 елда Мөхәммәдсадыйк хәзрәт Казан шәһәренең мөхтәсибе итеп сайлана һәм бу вазыйфаны 1924 елның гыйнварына хәтле башкара.

1931 елда М. Иманколый «кулак-муллалар төркеме»ндә катнашучы буларак кулга алына һәм биш елга лагерьга хөкем ителә. 1932 елның маенда Пермь өлкәсенең Красновишерск шәһәрендә авырып үлә; үлгәннән соң аклана.

Мөхәммәтсадыйк Иманколый – дини хезмәтләр, шигъри әсәрләр, дәреслекләр, сүзлекләр авторы. Иң танылган әсәрләре: «Сәләтыйн ислам…» («Ислам солтаннары…», 1909) дини трактаты, «Тәрҗеман руси, фарси вә төрки» («Русча-фарсыча-төркичә сүзлек», 1909), «Тәсһилел-бәйан фи тәфсирел Корьән» («Корьән тәфсиренең җиңеләйтелгән бәяны», Т. 1-2, 1910; 1996



елда Катарда репринт ысулы белән кабат басыла), «Мәрсия император Александр II вә тәһния император Николай II» («Император Александр II гә мәрсия һәм император Николай II гә котлау», 1910).

2000 елда М. Иманколыйның Казанда кулъязма хәлендә сакланган мөнәҗәтләре, газәлләре, касыйдәләре басылып чыга.



*М. Иманколый гаиләсе белән*

Религиозный деятель и поэт Мухаммадсадык Иманкулый родился 10 сентября 1870 года в Казани в семье муллы. Его детство проходит в Ново-Татарской слободе. В восемь лет он остаётся сиротой. Учится в медресе Казани.

В 1886 году М. Иманкулый для продолжения образования отправляется в Бухару, где учится восемь лет.

В 1894 году возвращается в Казань. Его назначают вторым имамом шестой мечети Ново-Татарской слободы, где он прослужит до 1932 года.




*«Тәсһилел-бәйан...» китабы*

В 1919 году Мухаммадсадык хазрат избирается мухтасибом Казани, занимает эту должность до января 1924 года.

М. Иманкулый был арестован в 1931 году как участник «кулацко-муллльской группировки», осуждён на пять лет лагерей. Скончался от болезни в мае 1932 года в городе Красновишерске Пермской области; был реабилитирован посмертно.

Мухаммадсадык Иманкулый – автор религиозных трудов, поэтических произведений, учебных по-







*М. Иманколыйның кульъязмасы һәм рәсеме*

собий, словарей. Наиболее известными его работами являются: религиозный трактат «Сәләтыйн ислам…» («Султаны ислама…», 1909), словарь «Тәрҗеман руси, фарси вә төрки» («Русско-персо-тюркский словарь», 1909), комментарий к Корану «Тәсһилел-бәйан фи тәфсирел-Коръән» («Облегченные пояснения к толкованию Корана», Т. 1-2, 1910, в 1996 году были переизданы репринтом в Катаре), «Мәрсия император Александр II вә тәһния император Николай II» («Элегия императору Александр II и ода императору Николай II», 1910).

В 2000 году в Казани опубликованы сохранившиеся в рукописи мунаджаты, газели и касыды М. Иманкулыя.

*Укырга тәкъдим итәбез:*
*Советуем прочитать:*

**Иманколый М.** Мөнәҗәтләр, газәлләр, касыйдәләр /төз., иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдин. – Казан: Иман, 2000. – 160 б.

**Иманколый М.** Газәл; Зарлану; Газәл; «Бостане Сәгъди»дән; Гыйбрәт: шигырьләр //Казан утлары. – 1998. – № 2. – Б. 142–145.

**Гайнетдин М.** Мулла шагыйрь //Казан утлары. – 1998. – № 2. – Б. 140–142.

**Гайнетдин М.** Юл читендә асылташ… //Мәдәни җомга. – 2000. – 22 сент. – Б. 17.

**Гайнетдин М.** Йөз елдан соң да урап кайта югалган авазлар //Шәһри Казан. – 2000. – 8 сент.

**Әхмәтҗанов М.** Шагыйрь һәм дин галиме //Мирас. – 1995. – № 9. – Б. 78.

**Нурмөхәммәтова Р.** «Тәрҗеман руси вә фарси вә төрки» сүзлеге //Мәгариф. – 2001. – № 5. – Б. 102–103.

**Ахунов А.** Мухаммад-Садык Иманкулый //Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2001. – № 3/4. – С. 149–153.

**15** сентябрь/ сентября



Таҗи Гыйззәт
Тази Гиззат
1895—1955

Тууына 125 ел
125 лет со дня рождения

Драматург, актёр, театр эшлеклесе Таҗи Кәлимулла улы Гыйззәт (Гыйззәтуллин) 1895 елның 15 сентябрендә Вятка губернасы Алабуга өязенең (хәзерге Татарстан Республикасы Әгерҗе районы) Барҗы Умга авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. 1910 елга кадәр авыл мәдрәсәсендә укый. Ул анда дини белемнән тыш дөньяви фәннәр дә үзләштерә.

Әтисе үлгәч, Таҗи төрле эшләрдә эшли. 1913 елда Ижау шәһәрендәге корал заводына урнаша, алты ел шунда хезмәт итә.

1919–1920 елларда Кызыл Армиядә хезмәттә чагында ул үзешчән сәнгатьтә катнаша; үзенең беренче шигырьләрен, пьесалар яза. Т. Гыйззәтне Самара шәһәрендәге хәрби округта ачылган татар драма студиясенә укырга җибәрәләр. Биредә ул актерлык һөнәрен камилләштерә, рус, Европа театр сәнгате тарихы һәм әдәбият белән якыннан таныша.

Укуын тәмамлагач, 1921–1929 елларда ул Оренбург, Казан, Ульяновск, Алабуга, Мәскәү шәһәрләрендәге театрларда артист, труппа режиссёры булып эшли. 1929 елда Казанга кайтып, 1950 елга кадәр Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында актёрлык хезмәтен дәвам иттерә. Ул рус һәм дөнья әдәбияты классикасы, татар драматурглары, үзенең




дә сәхнә әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә катнашып, истә калырлык, үзенчәлекле дистәләрчә образ иҗат итә.

Татар театр сәнгате тарихында Т. Гыйззәт барыннан да бигрәк үзенең әдәби хезмәтләре – сәхнә әсәрләре белән данлыклы. Аны драматург итеп таныткан әсәр – «Талир тәңкә» исемле драма – 1922 елда языла. 1923 елда Татар дәүләт театры сәхнәсендә куелып, тамашачылар тарафыннан яратып кабул ителә. Соңыннан драматург пьесага яңа образлар, яңа вакыйгалар өсти, әсәрнең исемен үзгәртә, ул «Чаткылар» дип атала башлый.

1923 елда тарихи темага «Каһәрле мөһер», 1925 елда «Наёмщик» пьесалары языла. «Наёмщик»ны әдип 1928 елда үзгәртеп эшли. С. Сәйдәшев музыкасы белән сәхнәгә куелган бу икенче вариант һәр ике авторга да танылу – популярлык китерә.

Т. Гыйззәт үз чорының көнүзәк мәсьәләләре, җәмгыятьтә, бигрәк тә авыл халкы тормышында барган социаль үзгәрешләр турында пьесалар иҗат итә. Аның «Мактаулы заман» комедиясе, «Бишбүләк» драмасы (С. Сәйдәшев музыка язган), «Ташкыннар», «Таймасовлар», «Төнге сигнал», «Изге аманәт», «Чын мәхәббәт» һ. б пьесалары бар.

Т. Гыйззәт либреттосы буенча (Х. Ибраһимовның шул исемдәге пьесасы нигезендә) «Башмагым» беренче татар музыкаль комедиясе (1942) языла (Җ. Фәйзи музыкасы). Бу әсәр Казан һәм башка шәһәр театрларында күп тапкырлар уйнала, тамашачы аны яратып кабул итә.

Үз гомерендә Т. Гыйззәт 37 сәхнә әсәре яза, рус теленнән дистәгә якын пьеса тәрҗемә итә, аның иҗат мирасында шулай ук татар театры тарихына, аерым сәхнә эшлеклеләренә багышлап язган тәнкыйть мәкаләләре, истәлек язмалары да бар.

Аңа 1939 елда ТАССРның, 1940 елда РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелә.

Таҗи Гыйззәт 1955 елның 7 мартында вафат була.

Драматург, актёр, театральный деятель Тази Калимуллович Гиззат (Гиззатуллин) родился 15 сентября 1895 года в деревне Варзи-Омга Елабужского уезда Вятской губернии (ныне Агрызский район Республики Татарстан) в семье крестьянина. До 1910 года обучается в сельском медресе, где одновременно с религиозным получает и светское образование.

После смерти отца Тази выполняет разную работу. В 1913 году устраивается рабочим на Ижевский оружейный завод, где работает шесть лет.

В 1919–1920 годах, в период службы в Красной Армии, принимает участие в художественной самодеятельности, пишет первые стихи и пьесы. Т. Гиззата направляют на учёбу в татарскую драматическую студию при Политуправлении Самарского военного округа. Здесь он приобретает профессиональные актерские навыки, знакомится с историей русского и европейского театрального искусства и литературы.

По окончании учёбы в 1921–1929 годах Т. Гиззат работает артистом, режиссёром в театрах Оренбурга, Казани, Ульяновска, Елабуги, Москвы. В 1929 году Т. Гиззат возвращается в Казань и до 1950 года работает актёром в Татарском государственном академическом театре им. Г. Камала. Сыграет множество ролей в спектаклях по произведениям татарской, русской и зарубежной классики, а также по своим драматическим произведениям, создав галерею незабываемых образов.



*«Бишбүләк» китабы*

В истории татарского театра Т. Гиззат известен прежде всего



*«Ил үскәндә» китабы*

своими драматическими произведениями. В 1922 году он пишет драму «Талир тәңкә» («Серебряная монета»). В 1923 году пьеса была поставлена на сцене Татарского государственного театра и тепло принята зрителями. Позже автор добавляет в пьесу новые образы и события, изменяет её название, так рождается его знаменитая драма «Чаткылар» («Искры»).

В 1923 году Т. Гиззат пишет пьесу на историческую тему «Каһәрле мөһер» («Проклятая печать»), в 1925 году – пьесу «Наёмщик», которую в 1928 году переделывает. Спектакль по второму варианту пьесы на музыку композитора С. Сайдашева идёт с большим успехом и приносит огромную популярность обоим авторам.

Одна из главных особенностей пьес Т. Гиззата – их острая социальная направленность. Драматург создаёт пьесы на злободневные социальные темы, особенно касающиеся жизни села, выступает своего рода художественным летописцем. Перу Т. Гиззата принадлежат пьесы «Мактаулы заман» («Славная эпоха»), музыкальная драма «Бишбуляк» (музыка С. Сайдашева), «Ташкыннар» («Потоки»), «Таймасовлар» («Таймасовы»), «Төнге сигнал» («Ночной сигнал»), «Изге әманәт» («Священное поручение»), «Чын мәхәббәт» («Настоящая любовь») и др.



*«Ташкыннар» китабы*

Т. Гиззат является автором либретто (по одноимённой пьесе писателя Х. Ибрагимова) первой татарской музыкальной комедии




«Башмачки» (музыка Дж. Файзи), которая завоевала широкую популярность и долгие годы с успехом шла на сценах театров Казани и других городов.

Т. Гиззат создал 37 сценических произведений, перевел на татарский язык около 10 пьес; в его творческом наследии представлены статьи по истории татарского театра, воспоминания, критические заметки, посвящённые театральным деятелям.

В 1939 году Т. Гиззату присвоено почётное звание заслуженного деятеля искусств ТАССР, в 1940 году – заслуженного деятеля искусств РСФСР.

Тази Гиззат умер 7 марта 1955 года.

*Укырга тәкъдим итәбез:*
*Советуем прочитать:*

**Гыйззәт Т.** Сайланма әсәрләр: 5 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. б.

Т.1: пьесалар. – 383 б.
Т.2: пьесалар. – 367 б.
Т.3: пьесалар. – 287 б.
Т.4: пьесалар. – 367 б.
Т.5: пьесалар, публицистика. – 335 б.

**Гыйззәт Т.** Пьесалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 383 б.

**Гыйззәт Т.** Сайланма әсәрләр: драмалар /төз. К. Гыйззәтов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 384 б.

**Әдипләребез**: биобиблиогр. белешмәлек. 2 томда. Т.1. [төз. Р. Н. Даутов, Р. Ф. Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 751 б. – Таҗи Гыйззәт. – Б. 419–422.








**Даутов Р. Н., Нуруллина Н. Б.** Совет Татарстаны язучылары: биобиблиогр. белешмә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 639 б. – Таҗи Гыйззәт. – Б. 141–145.

**Гыйззәтов К.** Таҗи Гыйззәт. Фикерләр. Истәлекләр. Хатлар. Бәхәсләр. –Казан: Мастер Лайн, 2000. –512 с.

**Ханзафаров Н.** Таҗи Гыйззәт //Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. Т.5: Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1941–1960). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 416–432.

**Миңнуллина Ф.** Таҗи Гыйззәт //Татар әдәбияты тарихы. 8 томда. Т.5: 1917–1956 еллар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – Б. 392–405.

**Гыйззәтов К.** Заман һәм кешеләр: истәлекләр, архив документлары, хатлар = Гиззатов К. Время и люди: воспоминания, архивные документы, письма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 335 б.

**Галимуллин Ф.** Рухи хәзинәләр гасыры: фәнни публицистик мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – 399 б. – Таҗи Гыйззәт иҗатында татар халкы язмышы мәсьәләсе. – Б. 150–155.

**Арсланов М. Г.** Татар театры: энциклопедик сүзлек-белешмә. – Казан: Заман, 2014. – 584 б. – Таҗи Гыйззәт. – Б.163–169.

**Арсланов Г.** Тылсым. Татар театры: режиссерлар һәм драматурглар. – Казан: Мәгариф, 2008. – 287 б. – Ташкыннарның көче…: (Таҗи Гыйззәт драматургиясе һәм татар театры). – Б. 270–275.

**Татар драматурглары**: биобиблиогр. белешмәлек /төз. Ф. Ганиева, Р. Яруллина, А. Саттарова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 271 б. – Таҗи Гыйззәт. – Б. 76–79.

**Гыйззәтов К.** Халык тормышын язды //Казан утлары. – 2005. – № 9. – Б. 165–173.



**Галимуллин Ф. Г.** Таҗи Гыйззәт иҗатында татар халкы язмышы; Миңнуллина Ф. Х. Т. Гыйззәт драматургиясендә шәхес фаҗигасе; Арсланов М. Г. Таҗи Гыйззәтнең иҗат эволюциясе; Шакирҗан Л. Г. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры репертуарында Таҗи Гыйззәт иҗаты; Хәйруллин И. З. Таҗи Гыйззәт иҗаты һәм периферия театрлары // Фәнни Татарстан. – 2015. – № 4. – Б. 130–134, 135–139; 140–148; 146–153; 154–156.

**Арсланов Г.** Үз театрын булдырган әдип //Мәдәни җомга. – 2015. – 18 сент. – Б. 17.

**Таҗи Гыйззәт** чаткылары һаман да яна //Сәхнә. – 2015. – № 9. – Б. 12.

**Арсланов Г.** Шаулы ташкын көче //Мәдәни җомга. – 2010. – 17 сент.

**Гыйззәт К.** Бу дуслыкның эзе тарихта калды: [С. Сәйдәшев белән Т. Гыйззәт дуслыгы] //Ватаным Татарсатн. – 2010. – 29 дек.

**Юнысова А.** Табылган «Башмак»: [«Башмагым» музыкаль комедиясе] //Идел. – 2009. – № 12. – Б. 52–54.

**Гиниятуллина А.** Писатели Советского Татарстана: биобиблиогр. спр. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. – 511 с. – Тази Гиззат. – С. 136–138.

**Гиззатов К.** Каким же был Тази Гиззат в жизни? //Татарстан. – 2005. – № 9. – С. 58–60.

**Шарипов А.** Литература народов Поволжья и Приуралья. Ч.1: Татарская литература: история и современность. – Наб. Челны, 2018. – 572 с. – Тази Гиззат. – С. 343–346.

**Хабибуллин Ф.** Театр Тази Гиззата: [эпизоды из личной и творческой биографии драматурга] //Республика Татарстан. – 2005. – 22 сент.

**Юнысова А.** Вновь обретенные «Башмачки»: [о постановке музыкальной комедии «Башмачки»] //Идель. – 2009. – № 12. – С. 53–55.





**10** октябрь/октября



Казан дәүләт консерваториясе
Казанская государственная консерватория
1945

Ачылуына 75 ел
75 лет со дня открытия

Н. Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе – Россия Федерациясенең Мәдәният һәм кинематография федераль агентлыгы карамагындагы югары уку йорты. РСФСР Халык Комиссариатлары Советы тарафыннан 1945 елның 13 апрелендә чыгарылган карар нигезендә оештырыла, 1945 елның 10 октябрендә эшли башлый.

Консерватория Урта Идел һәм Урал буе республикалары (Татарстан, Башкортстан, Чувашстан, Удмуртия, Мордовия, Марий Эл) өчен югары квалификацияле музыкантлар (педагоглар, башкаручы-җырчылар, композиторлар, музыка белгечләре) әзерләүче үзәк буларак оештырыла.

Профессорлар Г. Литинский, А. Леман, Н.Җиһанов җитәкчелегендә Казан композиторлар мәктәбе барлыкка килә. 1945–1988 елларда консерваториянең ректоры Н.Җиһанов була, 2001 елда уку йортына аның исеме бирелә.

Консерватория ачылганнан бирле фортепиано, оркестр, хор дирижерлыгы, вокал факультетлары эшләп килә, 1948 елда теоретик-композиторлык, 1961 дә халык музыка уен кораллары факультетлары ачыла. 1972 елдан органда уйнау өчен әзерлек курслары алып барыла. 1989 елда татар музыкасы кафедрасы эшли башлый. 1995 тә татар музыка сәнгате факультеты оештырыла.



Белем бирү программалары 8 факультет һәм 21 кафедрада үткәрелә.

Укыту уен коралларында уйнаучылар (фортепиано, орган, клавесин, арфа, кыллы оркестр уен кораллары, халык уен кораллары), дирижерлык итү (опера-симфония, академик хор), вокал сәнгате (академик һәм халык җырларын башкару), композиция, музыка белеме, этномузыкология, балет педагогикасы белгечлекләре буенча алып барыла.

Татарстан Республикасы Дәүләт симфоник оркестры, Татар опера һәм балет театры, Татарстан Республикасының җыр һәм бию ансамбле, Татарстан һәм Идел буе республикаларындагы башка әйдәп баручы коллективларның төп өлешен Казан консерваториясен тәмамлаган белгечләр тәшкил итә.

Консерваториядә студентларның төрле иҗади коллективлары эшли. 1960 елдан консерватория каршында махсус урта музыка мәктәбе эшләп килә.

Казан консерваториясе музыка сәнгате мәсьәләләрен өйрәнү буенча төп фәнни үзәк булып та тора. Музыкаль фольклор кабинеты Татарстан Республикасы районнарына һәм татарлар күпләп яшәгән урыннарга экспедицияләр оештыра. Төп фәнни юнәлешләр: Татарстанның хәзерге музыка мәдәнияте, төрки, фин-угор, славян халыкларының традицион музыка сәнгате һәм аларның үзара йогынтысы һ. б.

Консерваториядә 4 концерт залы, 3 орган бар. Укыту базасы сыйфатында Татарстан Республикасының Зур концерт залы файдаланыла.

1988 елдан консерваториянең ректоры – Р. К. Абдуллин.

Федеральное государственное бюджетное образовательное учреждение высшего образования «Казанская государственная консерватория имени Н. Г. Жиганова» создано распоряжением СНК РСФСР от 13 апреля 1945 года, начинает функционировать с 10 октября 1945 года. Директором Казанской консерватории был назначен композитор Н. Г. Жиганов, проработавший на этом посту до 1988 года. С 2001 года консерватория носит его имя.





Консерватория создается как центр подготовки музыкантов высшей квалификации (педагогов, исполнителей, композиторов, музыковедов) для республик Среднего Поволжья и Приуралья: Татарстана, Башкортостана, Чувашии, Удмуртии, Мордовии, Марий Эл.



*Нәҗип Җиһанов*

Казанская композиторская школа сложилась под руководством профессоров Г. Литинского, А. Лемана, Н. Жиганова. Со времени открытия учебного заведения работают фортепианный, оркестровый, дирижёрский, хоровой, вокальный факультеты, в 1948 году открыт теоретико-композиторский факультет, в 1961 году – факультет народных инструментов, с 1972 года ведётся подготовка органистов. В 1989 году открыта кафедра татарской музыки, а в 1995 году создан факультет татарского музыкального искусства.

Образовательные программы реализуются на 8 факультетах и 21 кафедре.

Обучение производится по специальностям: инструментальное исполнительство (фортепиано, орган, клавесин, арфа, струнные оркестровые инструментые, народные инструменты), дирижирование (оперно-симфоническое, академическим хором), вокальное искусство (академическое и народное), композиция, музыковедение, этномузыкология, педагогика балета.



*Натан Рахлин, Рубин Абдуллин*

Выпускники консерватории составляют основу Государственного симфонического





оркестра Республики Татарстан, Татарского театра оперы и балета, Ансамбля песни и танца Республики Татарстан и других ведущих творческих коллективов Татарстана и Поволжья. В консерватории действуют студенческие творческие коллективы. С 1960 года при консерватории работает специальная средняя музыкальная школа.

Казанская консерватория является ведущим научным центром региона по изучению проблем музыкальной культуры. Кабинет музыкального фольклора организует экспедиции по районам Республики Татарстан и в места традиционного проживания татар. Основные научные направления: современная музыкальная культура Татарстана, традиционные музыкальные культуры тюркских, финно-угорских, славянских народов и их взаимовлияние и др.

В консерватории имеются 4 концертных зала, 3 органа. В качестве учебной базы используется Большой концертный зал РТ.

С 1988 года ректором консерватории является Р. К. Абдуллин.

*Укырга тәкъдим итәбез:*
*Советуем прочитать:*

**Абдуллин Р. К.** Югары сәнгатькә юл /әңгәмәдәш һәм тәрҗ. И. Ибраһимов //Казан утлары. – 2015. – № 6. – Б. 142–145.

**Абдуллин Р.** Техас – Татарстан: белеменә караганда сыйфаты /әңгәмәдәш В. Шәрипов //Татарстан. – 2007. – № 1. – Б. 47–49.

**Халитов Р.** «Татар музыкасы Европаны сокландыра» /әңгәмәдәш Р. Низамиев //Идел. – 1999. – № 12. – Б. 66–67.

**Бәдигый Х.** Милли моңнар яшьлеге: [консерваториягә 65 ел] //Мәдәни җомга. – 2010. – 9 апр. (№ 14). – Б. 9.

**Музыка мәгарәсендә очрашу** //Мәдәни җомга. – 2003. – 25 апр. (№ 17). – Б. 24.

**Казанская государственная консерватория** (1945–1995). – Казань, 1998. – 269 с.

**Казанская государственная консерватория**: 65 лет творческого пути: материалы Междунар. науч. — практ. конф. (Казань, 2 октября 2010 года). – Казань, 2011. – 280 с.

**Казанская государственная консерватория** (Академия) имени Н. Г. Жиганова. 1945–2010: краткий биографический справочник. От А до Я. – 2-е изд., стереотип. – Казань, 2015. – 291 с.

**Из педагогического опыта** Казанской консерватории: прошлое и настоящее. – Казань, 1996. – 232 с.

**Из педагогического опыта** Казанской консерватории: прошлое и настоящее – Вып. 2. – Казань, 2005. – 376 с.

**Из педагогического опыта** Казанской консерватории: прошлое и настоящее – Вып. 3. – Казань, 2016. – 197 с.

**Актуальные проблемы** музыкально-исполнительского искусства: история и современность: материалы науч. — практ. конф. (Казань, 2 апреля 2008 г.). – Вып 1. – Казань, 2008. – 304 с.

**Казачков С. А.** Расскажу о времени и о себе. – Казань, 2004. – 64 с.

**Низамутдинова Ч.** 70 лет Казанской государственной консерватории им. Н. Г. Жиганова //Талант. – 2016. – № 24. – С. 56–59.

**Абдуллин Р.** Линия жизни Рубина Абдуллина /беседовала О. Туманская //Татарстан. – 2015. – № 4. – С. 72–73.

**Абдуллин Р.** У нас постоянно что-то происходит… /беседовала Е. Кривицкая //Музыкальная жизнь. – 2015. – № 3. – С. 72–76.

**Абдуллин Р.** Рождение музыки остаётся тайной /беседовала А. Нагорнова //Казань. – 2015. – № 4. – С. 62–66.

**Сальманова Г.** Храм наполненный музыкой //Идель. – 2005. – № 9. – С. 50–52.

**Хайрутдинов А.** Первые: [об истории создания] //Казань. – 2005. – № 5. – С. 15–17.

**Шарифуллина Н.** Школа Афзала Хайрутдинова //Казань. – 2004. – № 2. – С. 47–48.



**17** октябрь/октября



Әгъдәс Борһанов
Агдас Бурганов
1920—2018

Тууына 100 ел
100 лет со дня рождения

Тарихчы, тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы Әгъдәс Хөсәен улы Борһанов 1920 елның 17 октябрендә Бөгелмә кантоны (хәзер Татарстан Республикасының Лениногорск районы) Сарабиккол авылында туа. Балачак еллары Баулы районының Камышлы авылында һәм Бөгелмә шәһәрендә уза. Ульяновск өлкәсе Мәләкәс районындагы Рязаново авыл хуҗалыгы техникумында укый.

Ә. Х. Борһанов 1939 елдан 1947 елга кадәр Совет армиясендә хезмәттә була, Смоленск, Мурманск оборонасында, Төньяк Кореяне азат итүдә катнаша, Тын океан флотының Порт-Артур хәрби диңгез базасында (Кытай) хезмәт итә. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм сугышчан медальләр белән бүләкләнә.

1946 елда читтән торып Бөтенсоюз юридик институтын тәмамлый, 1954 елда М. В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының аспирантурасына укырга җибәрелә. «Октябрь революциясе һәм вак буржуаз партияләр» дигән темага диссертация яклап, тарих фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә ала.

1947–1948 елларда Әгъдәс Хөсәен Маргилан шәһәре хезмәт ияләре депутатлары башкарма комитеты секретаре, 1948–1949 да Үзбәкстанда Фирганә шәһәр прокуратурасы тикшерүчесе.




1949–1958 елларда Таҗикстанда башта юрист-консультант, аннары югары уку йортларында укытучы булып эшли.

1958 елдан Әгъдәс Борһанов Казанда, Казан авиация, Казан педагогия институтларында, Казан дәүләт университетында укыта.

1973 елда ул Мәскәүгә китә; башта Мәскәү гражданнар авиациясе инженерлары институтында укыта. 1979 елдан Мәскәү консерваториясендә эшли, 1985 елда профессор исеме ала; 1988 елда Мәскәү тарих-архив институтына күчә, әлеге институт 1990 елда Россия гуманитар университеты итеп үзгәртеп корыла.

Хезмәтләре Октябрь инкыйлабы тарихына, совет крестьяннары тормышына, философиягә, һәм милек социологиясенә, хәзерге замандагы милли мөнәсәбәтләргә һәм милли-мәдәни автономия мәсьәләләренә карый.

Ә. Борһанов Татар иҗтимагый үзәгенең 1нче корылтаенда (1989 ел), 2002 елда III Бөтендөнья татар конгрессында Мәскәү татарларыннан делегат буларак катнаша.

Әгъдәс Хөсәен улы Борһанов 2018 елның 8 ноябрендә Мәскәүдә вафат була. Казанның Арча зиратында җирләнә.

Историк, доктор исторических наук, профессор, почётный член Академии наук Республики Татарстан Агдас Хусаинович Бурганов родился 17 октября 1920 года в деревне Сарабиккулово Бугульминского кантона (ныне Лениногорский район Республики Татарстан). Детство проходит в деревне Камышлы Бавлинского района и в городе Бугульме. Заканчивает Рязановский (Ульяновская область, Мелекеский район) техникум сельского хозяйства.

А. Бурганов с 1939 по 1947 год служит в Советской армии, участвует в обороне Смоленска, Мурманска, в освобождении Северной Кореи, служит на военно-морской базе Тихоокеан-

ского флота в Порт-Артуре (Китай). Награжден Орденом Отечественной войны II степени и медалями.

